Шәһри Казан

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 3 ГЫЙНВАР, 2013 ЕЛ,
N 1 (5179)
WWW.SHAHRIKAZAN.COM

1990 елдан бирле чыга

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ҮТСЕН КИЛЕР ЕЛЛАРЫБЫЗ ТАЗАЛЫКТА, БАЙЛЫКТА



КӨН АВАЗЫ

Өметләр зурдан

Яңа елга аяк бастык. Гадәттә, ел башында кеше киләчәккә ниндидер планнар кора. Яңа уй-ниятләр, хыяллар белән яңа башлый. Ә сез Яңа елга нинди өметләр белән кердегез?

Филүсә АРСЛАН, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе:

– Өметләрем зурдан. Яңа ел алдыннан гына хастаханәдән чыктым. Быел чирләрем кабатланмасын иде дип телим. Ижади, милләткә файдалы фәнни эшләрем күп. Шуларны китап-җыентыклар итеп бастыру уе белән йөрим. Авылым тарихын өйрәнә һәм яза башлау теләге дә бар.

Искәндәр БИКТАҺИРОВ, Татарстанның халык артисты:

– Ел да шул бер өмет-теләк белән керәм инде мин Яңа елга. Илләр тыныч булсын, тормышыбызда ниндидер бер тотрыклылык барлыкка килсен, сау-сәламәт булыйк.

Резеда ХӨСӘЕНОВА, пешекче, аш-су остасы:

– Узган ел минем өчен бик нәтиҗәле булды. Ел ахырында гына «Тәмле булсын!» дигән китабымны эшләп бетереп, аны нәшриятка тапшырдым. Китабымның нәшер ителеп, халыкка таралуын телим. Декабрь аенда ресторанымны ачып җибәрдем. Ачу бер нәрсә, яхшы гына эшләп тә китсен иде дим. Яңа ел бөтен кешегә исәнлек-саулык, мул тормыш, гаилә бәхете алып килсен.

«ШК» газетасының 10 гыйнвар — пәнҗешәмбе санына алхәбәр

Зифа Кадыйрова: «Бу эшнең минеке түгел икәнен дә чамалыйм инде. Әмма кара эштән китәргә тырышу түгел иде ул. Мин хәзер дә китап басу өчен типография сораган акчаны шул кара эш белән шабаш эшләп җыям. Аның каралыгы мине оялтмый».

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА. «Минем көчем – көчсезлегемдә»

Эчкән кешенең хәленә керә белә дә инде Россия хөкүмәте. Менә бит, рәхмәт төшкере, бирәм дигән колына – чыгарып куяр юлына дигәндәй, хөкүмәт, Яңа ел бәйрәме уңаеннан, никадәр ял көне бирде. Бәгъзеләребез моңа бинһая шатланып, сабыйларча сөенеп, бәйрәмгә хәзерлек эшләрен ике-өч атна алдан ук башлады.

Ләбиб ЛЕРОН. «Махмыр»

«Күз тиюдән теге яки бу бөти генә коткара аламы, үзеңне үзең өшкереп аннан котылып буламы? Өшкергәндә нинди сүрәләр укырга кирәк?»

Дилбәр ГАРИФ. «Күз тию дөяне дә үтерә»

Атнага 3 тапкыр чыга торган газетаның индексы – 54126.

«Шәһри Казан»да бергә кайныйк! Телефоннарыбыз: (843) 562-50-07 (факс), 562-50-12

РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР

Иң матур стадион бездә булачак

КАЗАНДА яңа стадионның фасадын дөньядагы иң зур экран бизәячәк.

Казанда яңа футбол стадионы төзелешенә бәйле хәлне аңлату барышында ТР Премьер-министры Илдар Халиков шулай дип белдерде.

Илдар Халиков сүзләренчә, куплярнең, объектның тышкы кыяфәтенә карап, стадион төзелеше әкрен темплар белән бара дигән фикере дөрес түгел. «Стадион ул – 10 спорткомплекс диярлек була. Аның бәясе – якынча 13 миллиард сум. Ләкин ул мондый объектлардан арзанрак һәм кыска вакытта төзелә. Октябрьдә аны төзи башлаганга 2 ел булды. Ул инде тәмамлану стадиясендә, 2,5 ел эчендә һичшиксез төзелеп бетәчәк», – диде И.Халиков. Аның сүзләренчә, Россиянең иң эре реклама компанияләренең берсе белән контракт төзелгән, һәм яңа стадионның фасадында уникаль медиаэкран пәйда булачак. «Чистай урамы ягыннан стадионның бөтен ян стенасы HD сыйфатлы 4,2 мең кв метрлы экран булачак. Минемчә, ул дөньядагы иң зур экран, һәм шуңа күрә стадионның уникаль тышкы кыяфәте булачак», – дип билгеләде республика Хөкүмәте башлыгы. Экранны урнаштыру эшен киләсе елның февралендә башлау планлаштырыла.

Су бетеп тора

9 ГЫЙНВАРДА иртәнге 9дан 10 гыйнвар иртәнге 9га кадәр Казанның Вахитов районында, Щапов, Мөштәри урамнарында яңа салынган йортларны һәм ТР Язучылар берлеге бинасын шәһәр су үткәргечгенә тоташтыру эшләре үткәрелү сәбәпле, шактый йортка су бирелмәячәк.

Аерым алганда, бу уңайсызлыклар:

Маяковский ур. йортлары, Гоголь ур., 3а, 5, 1, 2, 4, Горький ур., 16, 16/7, Мөштәри ур., 1/65, 2/67, 2а, 6а, 7, 11б, 13, 13а,б,в, 15, 15а, 20, 22, 6, 8, 9, 9б,в,е, 10, 11, 11/43, 11а, 12, 12а,б, 11/40, 13/22, 14, 16, 20, 24, 26, Толстой ур., 1а, 5/28, 3, 4, 7/47, 15, Щапов ур., Маяковский – Курашов урамнары арасындагы йортлар, Бутлеров ур., Катанов тыкрыгы, Ульянов-Ленин ур., Щепкин ур., Овражная урамындагы йортларга кагыла.

Су тутырылган автоцистерналар Маяковский – Щапов ур., Маяковский – Бутлеров ур., Маяковский – Ульянов-Ленин урамнары чатларына куелачак. Вакытлыча уңайсызлыклар өчен казанлылардан гафу үтенеп, «Водоканал» предприятиесе 9 гыйнварга кадәр алдан ук су җыеп куярга киңәш итә.

Халыкка кирәкле үзәкләр

ТАТАРСТАНДА кан тамырлары авырулары буенча ярдәм күрсәтүче өч яңа үзәк барлыкка киләчәк.

2013 елда кан тамырлары авырулары буенча ярдәм күрсәтүче үзәкләр Казанда, Әлмәттә, Байлар Сабасында ачылачак. Бу хакта Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгында узган матбугат конференциясендә министр Айрат Фәррахов хәбәр итте. Аның сүзләренә караганда, 2008 елдан башлап республикада, инсульт-лар нәтиҗәсендә үлем күрсәткечләрен, шулай ук халыкның инвалидлыкка чыгуын киметергә мөмкинлек бирүче 15 кан тамырлары үзәге сафка бастырылган. «Әлеге үзәкләрнең, чыннан да, әһәмияте зур, без бу программаны алга таба да дәвам итәргә ниятлибез», – дип белдерде Айрат Фәррахов.

Яңа елда — яңача

ГЫЙНВАР аенда Кизнер һәм Канашка баручы электр поездлары яңа график буенча йөри башлый.

Горький тимер юллары матбугат хезмәтеннән хәбәр итүләренчә, электр поездларының расписаниесе 9 гыйнвардан үзгәрә. Мисалга, Казан – Кизнер маршруты буенча йөрүче поезд. Казан – Канаш – Казан маршруты буенча йөрүче поезд да 10 гыйнвардан яңача йөри башлый.

Уңышлар сезгә, егетләр!

«КАМАЗ-Мастер» Мароккодагы Africa Race ярышында старт ала.

Анда пилот Антон Шибалов, штурман Евгений Яковлев һәм механик Дмитрий Сотников составында Россия йөк автомобиле чыгыш ясый. Россия экипажы башкалар белән көндәшлектә Марокко, Мавритания һәм Сенегал территориясеннән үтәргә туры киләчәк. Раллиның гомуми озынлыгы – 5796 километр, ул – 11 этап. Раллиның финишы 9 гыйнварга планлаштырылган, ул Сенегал башкаласында – Дакарда узачак. 2013 елның 5 гыйнварында «Дакар-2013» раллие башлана. Анда «КамАЗ-Мастер» командасының 4 Россия йөк автомобиле катнаша.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның ЯҢА ЕЛ МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле ватандашлар!

Яңа ел – үзенчәлекле бәйрәм. Ул һәрвакыт якты өметләр һәм яңа ышанычлар белән бәйле. Салкын кышкы кичтә безне гаилә учагы җылыта, без якыннарыбыз һәм дусларыбыз белән бергә җыелабыз. Җылы бәйрәм атмосферасында киләчәк турында уйлыйбыз, үтеп баручы елга нәтиҗә ясыйбыз. Татарстан өчен 2012 ел әһәмиятле вакыйгаларга һәм яңа казанышларга бай булды. Республика күп күрсәткечләр буенча илдә алдынгы позицияләрдә баруын дәвам итә. Төзелеш, инновацияләр, сәламәтлекне саклау һәм мәгариф өлкәсендә зур эш башкарылды. Россия Президенты сайлаулары, җөмһүриятебез Конституциясенең егерме еллыгы

нәтиҗәләре республикада иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны саклауга, социаль-икътисади һәм рухи-мәдәни үсешкә омтылуны күрсәтте. Үтеп баручы елның күңелгә ятышлы һәм мөһим күрсәткече – соңгы ике дистә ел эчендә беренче тапкыр рекорд куйган туган балалар саны. Тарихи-мәдәни мирас елында без рухи байлыгыбызны һәм гореф-гадәтләребезне саклау өчен бик зур эш башкардык. Үтеп баручы елның фаҗигале вакыйгалары, дини һәм милли мотивларга нигезләнеп җәмгыятебезне таркатырга тырышу безне тагын да ныграк берләштерергә тиеш. Татарстан һәрвакыт үзенең толерантлыгы, милләтара һәм динара тынычлык яклы булуы белән дан тотты. Бу идеяләр Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Республикасы халыклары ассамблеясе форумнарында тагын бер кат хупланды. Киләсе ел экология һәм әйләнә-тирәне саклау елы дип игълан ителде. Без бу юнәлештә эшли башладык инде. 2013 ел – Бөтендөнья җәйге Универсиада елы. Бу илебез өчен бик әһәмиятле чара. Җөен Казан дөньяның спорт башкаласына әверелә́чәк. Универсиада мирасы озак еллар буена халыкка хезмәт итәр. Кадерле дуслар! Республикабызның барлык казанышлары – безнең уртак тырышлыгыбыз нәтиҗәсе. Күмәк эшкә үз өлешен керткән һәрберегезгә зур рәхмәтемне җиткерәм. Алда безне яңа эшләр һәм яңа үрләр көтә. Яңа ел киленә, гадәттәгечә, иң яхшы теләкләр яңгырый. Тормышлар мул, дөньялар тыныч булсын. Корычтай исәнлек, яхшы кәеф телим. Бәхет кояшы өйләрегездә беркайчан да сүнмәсен, гаилә учагы сүрелмәсен.

Яңа 2013 ел белән!

Мэр йортта тәртип урнаштыра

Казан шәһәре башкарма комитеты халык һәм энергия чыганаклары белән тәэмин итүче компанияләр арасында коммуналь түләүләрне турыдан-туры башкару тәртибенә күчү мәсьәләсен Татарстан Хөкүмәтендә күтәрергә җыена.

ТИКШЕРҮ

Дамир БӘДРИЕВ

Башкала мэрының коррупциягә каршы көрәш буенча киңәшчесе Ратмир Шәйдуллин идарәче компанияләрнең эшчәнлегенә анализ ясаучы эшче төркемнең тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырды. Утызга якын йортта гомумйорт чыгымнары (ОДН) 100 процентан да артырып билгеләнгән. Тагын 700гә якын йортта ОДН тарифы күтәрелгән. «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе мәгълүматларына караганда, Казандагы 4 мең күпфатирлы йортның 79 проценты гына гомумйорт приборлары белән җиһазланган. Анда да әле йортларның 56 процентында гына тәгаен исәпкә алу үткәрелә. Приборлар йә ватык, йә пломбасы булмау сәбәпле, 978 йортта кулланылган чыганакларны исәпләү, гомумән, башкарылмый.

«Азино-2» идарәче компаниясенә караган Минск урамындагы 20 нче торак йортта салкын су үткәргеч торбасы «транзит» рәвештә йорт аша чыгып киткән. Челюскин урамындагы 60 нчы һәм 64 нче, Ямашев проспектындагы 15/1 һәм 15/2 нче йортларда да шул ук хәл. Вишневский урамындагы 10 нчы һәм 12 нче йортларда бер йортның салкын су хисаплагычы әлешенә икенче йортның хисаплагычы тоташтырылган. Эсперанто урамындагы 12а һәм 12в йортларында чыганаклар белән тәэмин итүче оешмалар күрсәткән күләмнәр халыкка куелган күләмнәргә тәңгәл килми. «Иван» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять Һади Такташ урамындагы 117 нче йорт үткәргечләренә рөхсәтсез рәвештә сауна тоташтырган, шунлыктан 200 мең сумнан күбрәк зыян ясаган. «Водоканал» Ибраһимов проспектындагы 12 нче йортта салкын су чыгымнарының чамадан тыш зур булуын тикшергән.

Тикшерүләрдән соң «Уңайлы торак» идарәче компаниясе Четаев урамындагы 44 нче, Восстание урамындагы 29 нчы, Октябрь урамындагы 50 нче, «Вахитов районы» идарәче компаниясе Пугачев урамындагы 45 нче, Сәетгалиев урамындагы 3 нче, Гаспринский урамындагы 31 нче, Тукай урамындагы 102а һәм 10б йортларга кабаттан исәп-хисап ясаган. «Мәскәү районы» идарәче компаниясе Ш.Усманов урамындагы 35 нче, Лена урамындагы 4 нче, Восстание урамындагы 49 нчы һәм 83 нче, Ямашев проспектындагы 17 нче йортларга кагылышлы коммуналь түләүләрдәге кимчелекләрне бетергән. Шушы мисаллардагы кабаттан исәп-хисап күләме 400 мең сумны тәшкил итә.

Казанда күпфатирлы 1281 йортта ОДН, ягъни гомумйорт чыгымнары 1 проценттан да артмый. Мэр Илсур Метшин ОДН күрсәткечләре «аномаль» артырылган йортларның һәрберсен җентекләп тикшерергә кушты.

ОЧТЫ-КИТТЕ

ӘЙТКӘН СҮЗ — АТКАН УК

Илсур МЕТШИН,
Казан мэры:

— 7 гыйнварда барлык җитәкчеләргә дә эшкә чыгасы: бернинди тау чаңгыларында шуу, чит илләрдә комда кызынып ятулар юк.

(«Эшлекле дүшәмбе» киңәшмәсендә Яңа ел яллары көннәрендә эшне оештыруга карата әйткән сүзләре)

Җиде кат тикшер, бер кат кабыз...

КИСӘТҮ

Илсөя ЗӘЙНУЛЛИНА

Һава шартларын да әйтер идем инде... Әле чатнама суык, әле буран, әле карлы яңгыр ява. Аяк асты да бер туңдыра, бер җебетә шунда... Таныш моңзарлар, шулай бит. Адәм баласына ярап булмый инде, нишләтәсең. Һава шартларының үзгәреп торуы «Казаньгоргаз» оешмасын да борчый әле менә. Сезнең һәм безнең сәламәтлекне кайгыртулары инде, билгеле. Баксаң, коры салкын, җилле көннәрдә төтен һәм вентиляция юлларында үзгәрешләр килеп чыгарга мөмкин икән. Мондый көннәрдә газ мичен, колонканы яки автомат рәвештә эшли торган су җылыткычларын кабызыр алдыннан һәм кабызганнан соң 1-3 минутлардан төтен китү юллары әйбәтләп тикшерергә кирәк икән. Төтен тышка тартылмаган очракта, газ җиһазларыннан файдалану тыела. Индивидуаль торак йортларда яшәүчеләргә һәм торак фондка хезмәт күрсәтүче оешмаларга да игътибарлы булырга кирәк. Пар конденсатлары һәм төтен юлларына боз кату төтен юллыгының тараюына һәм газ янганнан калган калдыкларның тышка очмыйча, кире өйгә керү куркынычына китерә дип кисәтә «Казаньгоргаз» оешмасы.

Һәр өйгә бәхетне «Шәһри Казан» алып килә

Мансур МОРТАЗИН,
баш мөхәррир

Хөрмәтле укучыларыбыз! Һәр пәнҗешәмбе санында, шушы биттә, шушы урында без сезгә газетабызга язылырга чакырып мөрәҗәгать иттек. Бу Яңа елга күп яңа дуслар белән керәбез. Сүзебезне җилгә очырмаган өчен зур рәхмәт үзегезгә.

Бүген безнең тиражыбыз 8 меңнән артып китте. Бу сан безне, редакция хезмәткәрләрен, әлбәттә, бик шатландыра. Әле биш ел элек кенә газетаның тиражы 1700 данә иде. Чыннан да, «Ш.К.»-ның эчтәлегеннән дә, бизәлешеннән дә канәгать булмаучылар шактый булды. Сәбәпләре атта да, тәртәдә дә булгандыр. Хәзер без элеккеге еллардагы кебек хакимият карарларын басмыйбыз, газетаны нигездә сезнең теләкләрегезгә искә алып нәшер итәргә тырышабыз. Газетабызның якын дусты, даими укучысы Разил Вәлиев киңәшенә колак салып, үзебезгә күп кенә яшь каләм ияләрен җәлеп иттек. Талантлы, тырыш иҗат кешеләренә редакциядә һәрчак урын түрдән, канатланып иҗат итсеннәр генә! Танылган язучы, юмор остасы Ләбиб Лерон да хәзер безнең хезмәткәребез. Башка талантлы шәхесләребез белән хезмәттәшлек итәргә дә без һәрвакыт әзер.

«Ш.К.»ның даими укучыларыннан: «Сезне әле белеп җиткермиләр, газетаны халык арасында күбрәк танытасы иде», – дигән киңәшләрне еш ишетергә туры килә. «ТНВ» каналында барган рекламабызны күреп, илебезнең төрле төбәкләреннән «Сезгә ничек язылырга?» дип сораучылар саны артты. Нәкъ менә читтә яшәүче милләттәшләребезнең үтенечләрен искә алып, без быелдан Россия каталогына керәбез. Әгәр Татарстаннан читтә гомер итүче туган-тумача, дус-ишләрегез бар икән, аларны сөендерә аласыз: икенче яртыеллыктан башлап, «Ш.К.» аларның да өйләренә даими килеп торачак.

Телевидениедә күрсәтелгән рекламабызда «Ш.К. – өйгә бәхет алып килүче газета» диелгән иде. Чыннан да, шулай булсын, «Ш.К.» һәр өйгә, һәр укучыбызга бары тик бәхет кенә алып килсен!

Динә белән Эльмира — Татарстанның атказанган артистлары

«Беренче канал» оештырган «Голос» проектында катнашкан милләттәшләребез – Динә Гарипова белән Эльмира Кәлимуллина Татарстан өчен чып-чын Яңа ел бүләге ясады. Яшел Үзән кызы Динә Гарипова әлеге проектта – беренче, ә Түбән Кама кызы Эльмира Кәлимуллина икенче урынны алды. Җиңү яулаган Динәгә бүләк сыйфатында тавыш яздыру компаниясе белән биш еллык килешү тапшырылды.

АФӘРИН!

Динәнең әйтүенчә, проект дәвамында аңа әнисе һәм дуслары бик нык ярдәм иткән. Әнисе конкурс буена кызы янында Мәскәүдә яшәгән. Мине Мәскәү урамнарында таный башладылар, автографлар сораучылар да күп булды, ди иң яхшы тавыш иясе. Хәзер кыз тавышын ял иттерә һәм шул ук вакытта сессиягә дә әзерләнергә уйлый. «Проект вакытында тавыш гел киеренкелектә булды, хәтта сөйләшергә дә авыр. Шуңа да тавышымны ял иттерергә, берничә көн җырламаска булдым», – ди ул.

Икенче урынга лаек булган Эльмира Кәлимуллина сөйләвенчә, финал өлешеннән соң Динә белән аны бер дә уйламаган шалтырату көткән. «Башта Татарстанның Мәдәният министрлыгыннан, аннан Президент Аппаратыннан безгә Татарстанның атказанган артисты исеме бирелү турындагы хәбәрне ирештереп шалтыратулар бер дә көтмәгәнчә булды», – ди Эльмира. «Голос» проектының финалына чыккан Эльмира Кәлимуллина белән Казан мэры Илсур Метшин да очрашты. «Без сезнең җиңүегез өчен җан атып тордык. Эльмира өчен Казан гына түгел, бөтен Түбән Кама тавыш бирде», – диде Илсур Метшин. Мэр аңа һәм әнисенә – чәчәкләр, ТР Президентыннан Яңа ел бүләген тапшырды. Очрашуда Эльмира: «Татарстан исеменнән мондый зур шоуда катнашу – минем өчен зур бәхет. Татарстанның атказанган артисты исеме бирелү миңа зур җаваплылык өсти», – диде.

Укытучыларга һәм табибларга фатир бирәләр

Республикада социаль ипотекага охшашлы яңа федераль программа гамәлгә ашырыла башлаячак.

ТОРАК

ТР Дәүләт торак фонды башкаручы директоры Тәлгать Абдуллин сүзләренә караганда, шушы көннәрдә генә торак төзелешен үстерү буенча РФ Хөкүмәте комиссиясенең федераль әһәмияттәге җирләрне торак төзелеше өчен комплекслы үзләштерүгә кагылышлы карары дөнья күргән. Аннан күренгәнчә, алга таба әлеге җир участокларын торак-төзелеш кооперативларына тапшыру күздә тотыла. Татарстан әлеге программаны сынау зонасына керә. Яңа программа буенча 178 фатирга исәпләнгән беренче шундый йортны Казанның Горсоветская урамында төзү ниятләнелә. Проекты инде эшләнгән. «Федераль структуралар хезмәткәрләре, табиблар, мәдәният хезмәткәрләре, укытучылар шушы программа буенча тораклы булу мөмкинлеген ала. Бу программа социаль ипотека шартларын кабатлый», – дип ассызыклады ТР Дәүләт торак фонды башкаручы директоры.

Әкияткә — кунакка...

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында «Белоснежка и семь гномов» дип аталган Яңа ел программасы бара. Ул 30 декабрьдән башланып киткән иде инде. Нәниләр өчен тамашалар әле 8 гыйнварга кадәр дәвам итәчәк.

ТАМАША

Бертуган Гриммнар әкиятләре мотивлары буенча әзерләнгән балалар спектакльләре циклы – опера һәм балет театрының Казан хореография училищесы укучылары белән әзерләгән уртак проекты. Бәйрәм көннәрендә яшь артистлар көненә 2-3 спектакль күрсәтәчәкләр. Шунысын да әйтергә кирәк, опера һәм балет театрындагы Яңа ел тамашалары беренче чиратта яшь тамашачыга тәгаенләнгән. Күп кенә 3-4 яшьлек нәни казанлыларга бу классик сәнгатькә якынаюның беренче тәҗрибәсе, театрга беренче сәяхәт тә булып тора. Спектакльләр башланыр алдыннан һәм антракт вакытында фойега куелган биек матур чыршы янында нәниләрне Кыш бабай, Кар кызы һәм төрле әкият геройлары көткәнен дә истә тотыгыз. Хөрмәтле әти-әниләр! Әйдәгез, балаларыгызга серле театр дөньясын күрсәтеп, үзегез дә балачакка бер кайтып килегез әле!

АЙНУР ГАЛИМОВ

Саф кануннар, үзгәрешләр елы җитте

Чираттагы яңа елны башлап җибәрдек. Чыршы бәйрәмнәрен үткәрү, Яңа елны каршылау әзерлекләре ыгы-зыгысын, бөтен борчу-мәшәкатьләрне иске елда калдырып, яңа планнар, теләкләр, хыяллар белән 2013кә аяк бастык. Яңа ел үзенә хезмәт хаклары, пенсияләргә, яшәү шартларын яхшыртуга һ.б. кагылышлы бер кочак үзгәрешләр дә ияртеп килде.

Яңа ел үзе генә килми

2013 елга планлаштырылган күпчелек үзгәрешләр ел дәвамында чынга ашырылачак, әмма 1 гыйнвар иртәсеннән үк кайбер яңа кануннар гамәлгә керергә өлгерде. Иң куандырганы – минималь хезмәт хакы арту. 13 процентка үсеп, 4611 сум урынына ул хәзер 5205 сумны тәшкил итә. Шушы өстәмә 594 сум булдымы шатлык, дияр кайберәүләр. Алар өчен искәртеп китәм: минималь хезмәт хакы 2011 елның июнендә соңгы тапкыр артканда, ул 281 сумга гына үскән иде. Бу күрсәткечтән тыш, 1 гыйнвардан ана капиталы да артты, 387 меңнән ул 408 мең сумга чаклы сикерде. Яңа ел иртәсендә кайбер һөнәр вәкилләре дә, аеруча тикшерүчеләр белән прокурорлар үзләрен күпкә баерак хис итеп, уянып киттеләр, чөнки аларның хезмәт хаклары 1 гыйнвардан 100 процентка артты. Ел дәвамында аның күләменең тагын да артачагы көтелә әле.

Шулай ук 1 гыйнвардан гамәлгә кертелгән аракыга һәм сырага кагылышлы кануннар бик файдалы булса да, байтак россиялегә ошап ук бетмәс, мөгаен. Өченче көннән алып, бер шешә аракының минималь бәһасе 36 процентка – 125 сумнан 170 сумга чаклы кыйбатланды. Башка спиртлы эчемлекләрнең бәяләре дә шактый өскә үрмәләде. Сырага килгәндә, хәзер аның 7 градустан катырагын 0,33 литрлы тараларда гына сату рөхсәт ителә. Аны җәмәгать урыннарында, массакүләм мәгълүмат чараларында рекламалау, төнге 11дән иртәнге 8гә кадәр сату тулысынча тыелды. Аракы белән сыра янына наркотикларны да кыстырыйк. Яңа ел башыннан алып, наркотик матдәләргә бәйле җинаятьләр өчен җәзалар да бермә-бер кырысланды.

1 гыйнвардан гамәлгә кергән үзгәрешләр арасында түләүле медицина хезмәтләрен рәсмиләштерү, шәхси эшмәкәрләр өчен салым түләү урынына патентлар системасын кертү, һәрбер ятимне яхшы торак белән тәэмин итү, кайбер юл йөрү кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар арту кануннары да бар.

Елан елыннан тагын ниләр көтәргә?

Бу үзгәрешләрдән кала, безне ел дәвамында күңелгә ятышлы һәм ятышлы ук булмаган башка яңалыклар да көтә. Беренчеләренә пенсияләр арту керә. 1 февральдән хезмәт пенсияләренең күләме – 7, 1 апрельдән тагын 3 процентка үсәчәк. Социаль пенсияләргә дә өстәмә көтелә, 1 апрельдән ул 5,1 процентка артачак. Соңгыларына, мисал өчен, машина йөртү таныклыгына имтихан биргәндә, кагыйдәләр катгыйлануын кертергә була. Имтиханның теория өлешендә моңа кадәр 2 хата җибәрү рөхсәт ителсә, 1 февральдән гамәлгә керәчәк үзгәрешләр нигезендә, дөрес түгел җавап өчен булачак машина йөртүче өстәмә биш сорауга җавап бирергә тиеш булачак.

Зыян күрүчеләрнең хокукларын яклауны нәтиҗәлерәк итү өчен автомобильләрне мәҗбүри иминиятләштерү (ОСАГО) турындагы канунга да төзәтмәләр кертеләчәк. Зыян күргән кешенең тормышына, сәламәтлегенә тигән зарарны каплау күләме 160 меңнән 500 мең сумга кадәр, мал-мөлкәтенә кагылганыкы 120 меңнән 400 меңгә кадәр артыр дип көтелә. Моның иминият полисларының 25-30 процентка кыйммәтләнүенә китерәчәген дә әйтергә кирәк.

2013 елның февраль-март айларында РФнең яңа Гражданнар Кодексы эшли башлаячак. Ул керткән яңалыкларының берсе – ябык акционерлык җәмгыятьләрен бетерү, 1 июльгә кадәр алар җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләргә яки җитештерү кооперативларына үзгәртелергә тиешләр. 1 марттан торак фонды объектларын бушлай приватизацияләү тәмамлана. Бу үзгәрешләрдән тыш, быелдан илдә РФ гражданинының паспорт, машина йөртү таныклыгы, медицина полисы, банк картасы кебек документларын берләштергән универсаль электрон карта булдыру һәм бармак эзләре кергән чит ил паспортларын чыгара башлау эшләре дә күз алдында тотыла.

Ә 2013 елда Россия халкын көткән иң мөһим вакыйга – «Шәһри Казан» газетасының тиздән Бөтенроссия матбугат каталогына керүе. Җәйдән башлап, аны бөтен ил буенча яздыру мөмкинлеге туачак.

ЧЕБЕШЛӘРНЕ САНАР ЧАК ҖИТТЕ

Менә Яңа 2013 елга да аяк бастык. Тагын бер ел артта калды. Яңа елны барыбыз да зур көч туплап, яңа уй-ниятләр һәм хыял-максатлар белән башлап җибәрәбез. Әмма иң элек артка борылып карыйк әле: авыл хуҗалыгы өлкәсендә нинди уңышларга ирешелгән икән 2012дә? Узган ел турында искә төшерсәк, авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләүчеләргә бер дә җиңелләрдән булмады ул, зур тырышлык һәм хезмәт куюны сорады.

ЙОМГАК

Чулпан НӘҖИПОВА

Табигать безне төрлечә сынады: нәкъ кирәк булмаган вакытта корылык үзәкләргә үтте, уңышны җыю чорында, көне-төне яңгыры яуды. Көз айлары да җылы килеп, көзге уҗым культуралары өчен борчылырга мәҗбүр итте. Кыскасы, мәшәкатьләр җитәрлек булды. Дөрес, яңгырларның да үз файдасы бар: туфрак рәхәтләнеп дымга туенды һәм киләсе елга яхшы уңыш көтәргә өмет уятты. Чебешләрне көзен санyйлар дигән кебек, нәкъ менә Яңа елга аяк баскан мәлдә авыл хуҗалыгы өлкәсендәге уңышларыбызны һәм эшләгән эшләребезне барлыйк әле.

Иң күп сөт — ТАТАРСТАНДА



2012 елда авыл хуҗалыгы җитештергән продукция 155 млрд сумга тигез булган. Уртача климатлы елларда республикада, гадәттә, 4,5-5 млн тоннага якын бөртекле культура җитештерелсә (2011 елда – 5,2 млн тонна), быел бик авыр ел, корылык булса да, авыл хезмәтчәннәренең тырышлыгы нәтиҗәсендә 3,2 млн тонна икмәк җыеп алынды.

Ә терлекчелек белән эшләр ничегрәк икән соң? Республикабызда барлыгы 1,1 млн башка якын мөгезле эре терлек бар. Шуларның 403 меңе – сөтлебикәләр. Дуңгызларның баш саны исә 656 меңгә тигез. Кошларга килгәндә, алар 14,6 млн баш исәпләнә. Республикада 445 мең тонна ит, 1,1 млрд данә йомырка җитештерелгән.

Соңгы вакытларда сөт җитештерү бераз азаеп алса да, республикада әлеге тармакны үстерү буенча даими рәвештә эшлиләр. Ел буена 1 млн 935 мең тонна сөт җитештерелгән. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: Татарстан – 2012 елда сөт савып алу буенча Россия төбәкләре арасында иң алдынгы урынны алып тора.

Кәҗәләрем куандыра!

Кәҗә турында юньле сүз ишетмәссең инде ул: кәҗә мал түгел, имеш, киребеткән. Әмма кәҗә асраучы һәм бу эшен яратып башкаручы әлеге сүзләр белән һич кенә килешмәс. Республикабызда бүген инде кәҗә асраучылар күбәйде. Барлыгы 402 мең баш кәҗә һәм сарык исәпләнә. Әле кайчан гына Сарман районыннан **Фазыл СӘЛИМГӘРӘЕВ** тә республикабызда иң беренчеләрдән булып кәҗә асрый башлаган иде. Үрчетү өчен Ставропольдән токымлы кәҗәләр алып кайтуына да инде берничә ел узып киткән. Газетабыз укучыларын аның белән таныштырып киткән идек инде. Моннан соң шактый гына вакыт та үткән. Фазыл Сәлимгәрәевнең кәҗәләре нихәл икән һәм узган ел алар өчен уңышлы булганмы, быелга нинди планнар белән яшиләр? Сорашып карыйк әле.

– Уңышларым турында кычкырып сөйләргә яратмыйм, әмма узган ел яхшы булды дип әйтә алам. Мин мал җанлы кеше, шуңа күрә эшемне дә табыш өчен генә түгел, ә яратып башкарам. Сораучысы бар, продукцияне кая куйыйм дип аптырап йөргән юк үзе. Бүгенге көндә фермамда 303 башка якын сөт бирә торган кәҗәм бар инде. Әле менә күбесе бәрәннәргә тора. Быелга да планнар зурдан: менә тагын ике бина төзергә ниятләп торабыз. Казанда ачылачак агросәнәгать паркында да үз ноктабызны булдырырга уйлыйбыз.

Бигрәк тәмле бәрәңге...

Эх, бигрәк тәмле инде ул бәрәңге... Бүгенге көндә кибет киштәләрендә ризыклардан башың әйләнеп китәрлек булса да, аннан башка ничекләр генә яшәр идек икән?! Әле бер танышым Яңа ел табынына да чикмәнле бәрәңге пешерәм, аның кырыена бер ит кисәге дә куйсаң, әллә нинди кыйммәтле рестораннар да бер кырыйда торсын, дип кызыктырып алды. Аллага шөкер, «икенче икмәк»нең уңышы да елына карап быел зарланырлык түгел: барлыгы 1,5 млн тонна бәрәңге җыеп алынды. Республикабызда әле кыш буена җитәрлек бәрәңгебез бар. 2012 елда Арча районының «Кырлай» агрофирмасы тарихка иң күп бәрәңге уңышын җыеп алучы буларак кереп калды. Быел алар бер гектардан 450 центнер бәрәңге алып куандырды. Уңышны җыеп алу бер хәл, әле бит аны урнаштырасы да бар. «Кырлай» хуҗалыгында бу яктан эшләр ничегрәк тора икән. Хуҗалыкның җитәкчесе **Илшат ШАКИРҖАНОВ** үзләренең эшләре, алдагы елга планнары белән таныштырды:

– Аллага шөкер, бәрәңгене урнаштырып барабыз. 40 тоннага якынын Казанга балалар бакчаларына җибәрдек. Шулай ук кибетләргә, хастаханәләргә урнаштырдык. Кыскасы, кая куярга икән моны дип утырган юк. Сорап, килеп алып торалар. Планнарга килгәндә, икенче бина ясап, шунда бәрәңгене пакетларга тутырып сатарга уйлап торабыз. Алай иткәч, сатучыга да, алучыга да уңайлырак булыр дип уйлыйбыз. Бәрәңгене саклый торган махсус биналарыбыз уңышны язга хәтле сакларга мөмкинлек бирә.

ЯҢАЛЫК

Төп бурыч — ризык чисталыгы

Татарстан авыл хуҗалыгы белгечләре Россия күләмендә иң-иңнәр булып санала. «Россельхозцентр»ның Татарстандагы бүлекчәсе дә үсемлекләрне саклау юнәлешендә беренче урында тора. Шунысы мөһим: әлеге үзәк үсемлекләрне генә түгел, ә безнең сәламәтлекне дә кайгырта. Менә Яңа ел алдыннан гына әле «Россельхозцентр»ның Татарстандагы бүлекчәсе базасында экологик чиста азык-төлек җитештерү буенча мәгълүмати-методологик үзәк ачылды.

«Бүгенге көндә яшелчә, җиләк-җимеш җитештергәндә, агулы матдәләр чамадан тыш кулланыла. Аларның барысын контрольдә тотып бетерә дә алмыйбыз. Ә бит ул кеше организмына бик зур зыян сала», – диде «Россельхозцентр»ның Татарстандагы бүлекчәсе җитәкчесе Таһир Һадиев. Ул таныштырып киткәнчә, яңа үзәкнең төп бурычы – җитештерүчеләр арасында экологик чиста продуктларны популярлаштыру. Оешма үсемлекләр өчен файдалы химик һәм биологик матдәләрне кеше сәламәтлеге өчен куркыныч булган агулы эшләнмәләрдән аера белергә өйрәтү эше белән дә шөгыльләнәчәк. Шулай ук монда халыкны экологик чиста продукция җитештерү юлларына да өйрәтәчәкләр. Таһир Һадиев әйтүе буенча, әлеге үзәккә шәхси хуҗалыклар, фермерлар, авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре генә түгел, ә гади халык та мөрәҗәгать итә ала.

Кайтам булгач, кайтам!

БЕЗНЕҢ ПОЧТА

Рифгать ЗӘКИЕВ,
Мамадыш

Быелгы салкыннар миңа 1978 елны хәтергә төшерде. Соңгы тапкыр нәкъ менә шул елны коточкыч салкыннар булган иде. Ул елны хәтта имәннәр дә өшеп корып бетте. Шул елдан соң чикләвек тә үсми башлады безнең якта. Шуңа да карамастан, Казаннан авылга Яңа ел каршыларга кайтып киттек бит. Студент еллары иде бу. Иң соңгы автобус сәгать кичке тугызда гына китсә дә, авылга кайту теләге бик көчле булган, күрәсең.

Авылыбызга хәтле өч сәгать кайтырга кирәк. Кайтып барабыз шулай әкрен генә. Автобус эчендә борылырлык та урын юк – шыгрым тулган. Бар да авылга агыла – Яңа ел каршыларга. Тик берәр сәгать чамасы баргач, автобусыбыз ватылып калмасынмы – басу уртасында. Нишләргә?! Машина килгәнен көтеп утырсаң, автобус белән бергә катып бетәргә мөмкинсең – 45 градус бит! (Әле бүгенге 20 градуста да көчкә йөрибез). Безнең бәхеткә, якында гына ярты километр чамасы ераклыкта бер авыл бар иде. Автобусны шунда этеп барырга булдык. Аны төзәтер өчен паркка кертеп куйдык та үзебез бер ферма өенә кереп урнаштык. Газ баллоны алып килделәр, газ плитәсе бар иде. Кулларны-аякларны шунда куеп җылыттык. Бераздан, автобусны рәтләп булмый, хәзер Казаннан икенчесен җибәрәләр, дип хәбәр иттеләр. Көтеп торыр чама юк, тизрәк кайтасы килә. Берәр машина очрамасмы дип өметләнеп, без, берничә егет, тагын юлга чыгып киттек. Ике-өч машина узып китсә дә, туктаучы гына булмады. (Бәйрәм вакытында нинди буш машина булсын инде?! Нинди җүләрләр бу дип карап кына уздылар алар.) Кире теге ферма өенә чабарга туры килде. Барыбыз да Яңа елга кайтучылар бит, шуңа күрә сумкаларда тәм-том күп иде ул көнне. Шулай итеп, Яңа елны ферма өендә каршыларга туры килде: 45 градус салкында, таныш булмаган бер авылда, ягылмый торган ферма өендә...

Төнге сәгать бер була дигәндә, ниһаять, Казаннан автобусы да килеп җитте. Өйгә кайтып төшкәндә, иртәнге сәгать дүрт иде инде. Аяк-бармаклар өшеп беткән, Яңа ел бәйрәмнәре дә узган... Әмма шундый маҗаралардан соң үз авылыңда, үз өеңдә, җылы юрган астында булу – әйтеп бетереп булмый торган зур шатлык һәм бәхет иде безнең өчен!

Авылда Яңа ел каршылыйм дип, кичке сәгать тугызда, 45 градус (!) салкында юлга чыгып китәр идегезме?! Ә без менә киттек...

Фотолар бизәү өчен бирелә

Сәхифәне Чулпан НӘҖИПОВА әзерләде

Әйтер сүзем бар

– Аныкы алда әле, бөтен гомере буе үзенә-үзе рәхәтлекләр тудырып яшәр, ә минем гомер кыскарып килә, – диде әни кеше, кырыс кына. – Нинди яңа күлмәк аңа, ике ел элек алганына да сыя әле, кисен. Баллы күчтәнәчнең хөкүмәт биргәне дә бик җитә. Кем белә – әллә үскәч кадерле ул мине, әллә бөтенләй кирәксезгә әйләнәчәкмен.

Баланыкы — алда, үземнеке — канда...

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

Яңа ел алдыннан шабыр тиргә батып, кибетләр буенча чапкан мин юләргә җитә калды, имәнеп урта яшьләрдәге хатынга төбәп әйткәнемне сизмәдем дә: «Мин сезнең балагыз булсам, үскәч кадерләмәс идем». Кылган изгелеген, баласына тудырган шатлыгын мыскалга салып үлчәрлек булгач, ни пычагыма үзеңне әни санап йөрисең инде син? Тәч-тәч талашырга торучы да булып чыкты әле үзе, гөпелт кабынып тезеп тә китте: «Мин балачагымда бернинди бәйрәм, бернинди бүләк күрмәдем әле. Үстем. Хәзер көн-төн чабып эшләп, ник бала хакын уйлыйм ди мин? Ашатуын ашатам, әмма артык бер тиенлек күлмәк тә, кәнфит тә күрмәячәк. Артык акчам булса, мин үз күңелемне үзем күрәм – әнә яңа күлмәк алырмын, акча янчыгының кыйммәтлесенә кызыгып йөрим»...

Балачактагы яралары бәла икән – хәзер үчен баласыннан алмакчы берәү.

Әни, сине Кыш бабай күрмиме әллә?

Үзенә тезелеп киткән бүләкләрне актарып, ике яшел күзен очкынландырып елмайган кызым шулай сорап куймасынмы миннән. Шулай булмыйни – балалар бакчасына килеп киткән Кыш бабай да бүләген калдырган, Кыш бабай заказларын үтәүче өйдәгеләр дә кимен куймаган, ике якта ике дәүәни һәм дәүәтиләр бүләкләре, акыллы кыз булганы өчен яңа күлмәк тә кайтып утырган... Әнине бераз жәлләп тә куярлык шул. Беләмени инде ул нарасый әнә шул ике яшел күздәге очкынның әни кеше өчен никадәр зур бүләк, никадәр зур сөенеч икәнен! Үземә бирелгән бүләкләрнең берсе дә аны алыштыра алмый шул. «Кыш бабай сине тәрәзәдән карап тора, әйбәт кыз икәнеңне күрсә, чыршы төбенә бүләкләрен калдырып китәчәк», – дигәч тәрәз янынан үткәндә йөргән адымнарга кадәр үзгәрде бит үзебезнең. Бүген әнә нинди бәхет баскан тәти кызны. Әмма алай да әнисен онытмый багалмам – Кыш бабайның әнисенә аныкы кадәр үк бүләк алып килмәве күңелен тырнап тора.

Яңа елга, Кыш бабай алып килүче могҗизаларга кеше ике чорда ышанып яши инде ул – балачакта һәм үзе әти-әни булгач. Мин балачакның ул могҗизалы чорына тәфсилләп тукталып тормыйм анысы, бездә дә аның кадәр Кыш бабайлы чор булмагандыр. Мәктәпкә килеп, тәм-том, берике алма-мандарин тоттырып китсә, авыл баласына тагын ни кирәк? Миңа аның бүгенге чоры – әни булгач Кыш бабайга ышана башлавым кадерлерәк. Шабыр тиргә батып кибеттән кибеткә йөгереп бүләк эзләү, өйдә шуны балаң тапмаслык итеп яшерү, Яңа ел төнендә берең баланы әвертеп, икенчең ялт кына чыршы төбенә ул сораган бүләкне кую, аннан тәрәз каккан тавыш чыгарып, балаңны чыршы янына чакыру!.. Аннан тизрәк фотоаппаратың белән иң кадерле мизгелләрне гаилә тарихына теркәү. Юләр, шундый мизгелләр хакына ни генә бирмисең ди. Монда кем акча санап торсын да, балага күпме китте дә, үземә күпме тоттым дип баш ватсын...

Ана күнеле — балада

Баланыкы да далада түгел. Теге кибеттә күреп сөйләшкән хатынга да шул ук сүзләрне әйттем мин. Мәхәббәттә, матурлыкта, әти-әни кадерендә үскән бала мәгънәсез була алмый ул. Киресенчә, матур балачак, кадерле мизгелләр тудырырга тырышкан ата-анасына карата миһербансыз да булмыйдыр дип чамалыйм. Аны юкка гына психологлар да ата-ана баласын көненә ким дигәндә 12 тапкыр битеннән үбәргә тиеш, димәгәннәрдер. Акча дип чукынып китеп, аның очына чыгып утырасы килми инде – бала, аның шатлыгы аннан мең артык. Булгән дә алабыз, туган көнен дә уздырабыз, менә хәзерге күптин-күп Яңа ел каникуллары чараларына да алып барабыз. Аллага шөкер. Мин аңа менә шушыны бирдем, ул кайтарып бирерме икән, дип уйланып утыра башласаң, үзеңне дә, балаңны да газаплап бала алып кайтып утырма инде син. Көзгедән үз-үзеңә гашыйк булып утыр да, бар эшләп тапканыңны үзеңә туздыр. Әмма рәхәтен генә күрерсеңме икән? Ә тапкансың икән, әни кеше бул инде – балаңның балачагын рәхәт, күңелле, бәхетле мизгелләргә коендыр. Шул вакытта җирдә дә изгелек артыр...

Ватылмый торган күкәй

Гөлнара ГАЛӘВИЕВА

Балаларны да алдыйлар. Әмма аларны, бездән аермалы буларак, ике кат алдап булмый...

Тычкан асылынырлык ук шыр буш түгел түгелен, әмма миңа кирәкле нәрсә – йомырка юк суыткычта. Аның урынына, кукыраеп, киндер-күкәйләр тезелешеп киткән. Бәләкәй кеше – кызым, миңа караганда да остарак итеп, телефоннан әтисенә әмер биреп кенә тора. «Кайчан кайтасың әле, әтием? Кибеткә керә калсаң, киндер-күкәй ал әле, ярыймы». Минем шул ук телефоннан әйткән исемлектәге ярты әйбер онытылып калырга да мөмкин, ә теге берсе-берсе 37-55 сум торган кибет күкәйләре кайтып тула. Ишек төбендә үк рәхмәтен чуты-чуты үбеп аңлаткан кызыма карап, мин дә елмаям.

Алабыз инде, алабыз. Ул киндер-күкәйнең бер файдасы булмаса да (аның шоколады ашалмыйча өстәлдә каңгырып йөрийөри дә чүп чиләгенә оча әле), баланы сөендерер өчен, өйдә аның өзелеп торганы юк. Өч-дүрт күкәй урынына берәр кулга тотарлык уенчык та алып булыр иде. Әмма әллә рекламасы шуның кадәр популярлаштырды аның, әллә шоколад эченнән яки кырыеннан чыккан вак уенчыкы ошый балаларга – нәрсә кирәк дигәндә, киндер-күкәй булсын.

Иң башта чыкканнары әле кызыклы да, бәясенә карата эчтәлеге дә ярыйсы кебек иде. Хәзергеләренең исә тышы бар – эче юк дигәндәй... Сайлап-сайлап алган буласың, бишесенең өчесендә бер үк пазл була да куя. Бу ни хикмәт инде? Энә күзе чаклы катыргы кисәкләрен 2-5 яшьлек бала тезеп утыра димени?! Димәк, тышы да, эче дә чүп чиләгенә дигән сүз. Сюрприз дигәннәре шуңа барып тоташа да. Баланың игътибарын хет унбиш минутка булса да үзенә юнәлтә алырлык вак уенчык тыксалар да начар булмас иде югыйсә!...

«Миңа киндер-күкәй башка ошамый», – диде әле кызым да, инде фәләненче кат бер үк кечтеки генә магнит кисәге чыгуга бөтен кәефе кырылып төшкәч. Баланы бит аны бер үк әйбер белән ике кат алдап булмый. Юк-бар уенчык кисәге чыкса, кош тоткандай йөри торган бәгырь җимеше хәзер сорамый да ул күкәйләрне. Дөрес, әле суыткычта ишеген ачуга шалтырап йөргәннәре бетеп өлгермәде. Мин әйтәм: боларын ачып, ташлап бетерик тә инде, бәлки, ул урынга әтиебез, кибет йомыркасы түгел, ә тавык йомыркасы алып кайтып тутырыр...

Дөнья бетми, акча бетә

Дөнья бетә дип куркыттылар куркытуын, Аллага шөкер, дөньясы да бетмәде, Яңа елга да аяк бастык. Дөнья бетү ыгы-зыгысыннан соң икеләтә бәйрәм булды инде бу. Шырпышәмнәр белән «коралланып», ныклап бәйрәм итәргә әзерләнгән идек югыйсә. Яңа ел төнендә утсыз гына утырырга туры килмәгә дип, үземнең беркатлылыгым белән мин дә соңгы көнне генә шәм сорап йөргән идем йөрүен

Фәнис МОТЫЙГУЛЛИН

Әмма Мәһди килер вакыт җитмәгәч, Дәҗҗал чыгарга уйламагач, яңа елларны күрергә насыйп булган икән.

Яңа ел шундый бәйрәм бит инде ул – могҗиза көтә-көтә төне буе ашап, аннан соң көне буе йоклау. Тора-бара гыйнварның беренче числосын йокы көне дип билгели башларбыз, мөгаен, бәйрәмнәрне уйлап табарга хирыс халык бит без.

Дәҗҗал дигәннән, хәдисләрдә: «Ахырзаман җиткәндә, гайбәтләр, ыгызыгы, сынаулар күп булачак», «җир тетрәүләр еш булыр, вакыт тиз үтәр, үтерешләр еш булыр», диелә. Җир йөзендә килеп туган ыгы-зыгыда Дәҗҗалның килүе шатлыклы вакыйга булачак. Әстәгъфирулла тәүбә, дөнья бетү ыгы-зыгысыннан соң гөрләтеп бәйрәм итүебез дә шул уңайдан гына түгелме икән? Уйлап карасаң, кешеләр үзләре уйлап чыгарган бу бәйрәм күптән гөрли инде, Дәҗҗал күптән безнең арадамы икәнни?

Бәйрәм итү кызык нәрсә үзе, әмма һәрнәрсәнең чамасы булырга тиеш. Ничек кенә булмасын, Яңа ел – акчаны җилгә очыру өчен менә дигән бер чара инде ул. Декабрьнең әнҗе карларына кушылып, буран кебек бөтерелеп-бөтерелеп оча акча. Акчаны җилгә очырырга кем куша дисезме? Шул инде, Дәҗҗал үзе. Әллә нинди бәйрәмнәр уйлап табып, сәбәпләрен чыгарып тора, алай гына да түгел, ул хәзер үзе шул акчага кереп яшеренгән тәсле. Кешеләрне гомер бакый талаштырып, ызгыш-сугышлар китереп чыгаручы әлеге дә баягы гел шул акча инде.

Дәҗҗалны тасвирлаучы төп билге – аның бер күзле булуы. Бүгенге көндә бала-чага да әйтеп бирә алачак – дөньяда Америка доллары хакимлек итә, дөньядагы барлык илләрнең диярлек икътисады доллар курсына бәйле. Бер долларлык банкнотның клишесы АКШның булачак вице-президенты Генри Уоллес боерыгы буенча Сергей Макровский (эмигрант Николай Рерих) тарафыннан ясала. Бу банкнотта унөч ярустан торучы пирамиданың очында өчпочмак формасында бар нәрсәне күрүче күз сурәтләнгән! Әлеге билге астына унөч хәрефтән торган «Annuit Coeptis» дигән латинча язу урнаштырылган. Әлеге сүзләрнең тәрҗемәсе – «Сайланган сыйныфка дөнья белән идарә итү билгеләнгән». Банкноттагы пирамиданың әһәмияттен «Novus Ordo Seclorum» дигән латин язуы («Гасыр буена яңа тәртип») да раслый.

Вәт менә шулай, ышанмасагыз, бер долларлык купюраны үзегез алып карый аласыз. Тагын кызыклы факт – купюраның киңлеге 666 миллиметр. Өч алтылы саны Тәүрат (Библия) китабында Дәҗҗал билгесе дип әйтелә! Украинаның 500 гривенендә да

шундый ук күз ясалган. Украинаның череп баюы ишетелмәде әлегә, ялган Дәҗҗал да була, күрәсең. Ә менә бөтендөнья финанс структурасының нигезен тәшкил итүе белән доллар Американың Дәҗҗаллы асылын билгеләвен исбатлап торасы да түгел.

Кем әйтмешли, бәйрәм килә дә китә, ә ашыйсы һәркөнне килә. Яңа ел каникуллары озын әле, әйләнәбез дә кибеткә барабыз, барган саен акча янчыгына үрелербез. Кесәдә долларлар да юк үзе, әмма акча чыга да оча, чыга да оча инде. Монда минем баш кына җитми, каләмдәшем Дилбәр әйтмешли, мандаринны кабыгы белән ашап карамыйча булмас, ахры.

Иң курыкканым – ялгызлык! Олы яшьтәге кешеләрдән бик еш ишетергә туры килә бу сүзләрне. Картаймыш көнеңдә кара-каршы утырып рәхәтләнеп чәй эчәргә иптәшең, сөйләшергә-киңәшергә якыннарың булмаса, моның никадәр авыр икәнлеген үзе шундый хәлдә калган кеше генә аңлыйдыр, мөгаен. Эшлисе эшләнгән, инде балалар да үсеп кайсы кая таралышып беткән вакыт. Иртәме-соңмы һәрбер кеше диярлек ялгызлык ачысын тоярга мөмкин.

ЯЛГЫЗ булырга ЯЗМАСЫН!

Чулпан НӘҖИПОВА

Күршебездә бер әби яши. Ул да ялгыз. Тормыш иптәше вафат, берданбер улы үлеп киткәнгә дә инде күп еллар узган. Әллә нигә бер безгә дә кереп чыккалый ул: «Бер үзем булгач шундый авыр. Әрлебирле тик йөрим шунда. Чәем чәй түгел. Ярый шул телевизор бар инде. Карамасам да, сөйләп утыра, кеше тавышын ишетү бераз тынычландырып җибәрә», – дип, кергән саен моңсуланып ала, күзләреннән яшь бөртекләре дә тәгәрәшеп төшә. Тагын бер ялгыз калган әбинең: «Янымда ичмасам бер мәче генә булса да сырпаланып торсын иде. Сөйләшмәсә сөйләшмәс, бер җан иясе генә булсын», – дигәннәре әле дә исемдә. Нигәдер авыл җирендә яшәүчеләргә бу яктан аз булса да җиңелрәк кебек тоела. Анда да ялгыз кешеләр җитәрлек, әмма аларның болай кайгырып утырганнарын хәтерләмим. Шәһәр әби-бабайлары дүрт стена арасында атналар буе да бер кеше күрми бит кайвакыт. Ә авылда күрше-күлән һәрвакыт бер-берсенең хәлен белеп тора. Тәм-том пешерсә дә, ялгыз күршесен сыйламыйча калмый. Авылыбызда күршедә ялгызы гына торучы бер әби бар. Аның янына керсәң, тик утырган чагын бер дә күрмәссең. «И, кызым, бернәрсәгә өлгерә алмыйм. Көннең үткәнен дә сизмим. Әнә ипигә дә күршемне җибәрдем, алайса намазымны укырга да өлгерми кала идем», – ди ул. Һаман нәрсәдер җыештыра, тәртипле, ул арада тавык-чебешен карап керә. Җәй булса, чүп утый, кыш булса, сукмак сала. Аның моңаеп утырырга вакыты да юк.

Олы кешенең ялгызы калып, кайгыга бирелеп утыруын аңлап була әле. Бүгенге заманда ялгызлыктан интегүче егет-кызлар да бик күп. Мондый ялгызлыкның сәбәпләре итеп белгечләр үзбәяң бик түбән булу, ниндидер уңышсызлыкка очраудан курку, аралаша белмәү һ.б. әйтә. Хәер, бүген ялгызлык турында уртак бер фикер дә юк. Кем өчендер ул газап булса, икенче берәүләр өчен ирек булып тора. Ялгыз яшәвең уңайлырак та, җайлырак та кебек: кемнедер хәстәрләп-кайгыртып мәшәкатьләнәсе түгел. Әмма алда ялгыз картлык та көтә бит әле...

Кеше белән аралашудан курыкмагыз

Рөстәм ИБӘТОВ, психолог:

– Ялгызлыкны ничек җиңәргә дигән сорауга җавап биргәнче, иң элек аның ни дәрәҗәдә булуын билгеләп үтәргә кирәк. Башта кеше үзен ташланган, бер кешегә дә кирәк түгел итеп хис итә. Ул бу ялгызлыкны ничек җиңәргә кирәклеген белми, шуңа күрә үзендә бушлык тоя. Алга таба исә кеше җәмгыятьтән, аралашудан бөтенләй читләшә. Бу вакытта ярдәм кулы сузмасаң, кеше үзенә, ялгызлыкны ничек җиңәргә, дигән сорауны бирми башларга да мөмкин. Ул үз язмышы белән килешә. Менә монысы начар да инде. Ялгызлыктан ничек котылырга, дисезме? Беренче киңәш, белгечкә барыгыз. Аннан соң кеше белән аралашудан курыкмагыз. Хәтта теләгегез булмаса да, сөйләшергә кирәк, туганнарыгыз белән дә ешрак күрешегез. Күңелегезгә ятышлы булган шөгыль табыгыз. Иптәшкә берәр йорт хайваны алып кайтсагыз була: аны тәрбияләп карап торырга кирәк, шул рәвешле сезнең, мин ялгыз, дип утырырга вакытыгыз да булмаячак. Кибетләрдә йөреп керү, башыгыз белән берәр катлаулы эшкә чуму да ярдәм итми калмас.

Ислам динендә ялгызлык турында нәрсә диелгән? Бу хакта без «Казан нуры» мәчете имам хатибы Алмаз хәзрәт МӨХЛИСОВтан сорадык.

– Ялгызлык ул бик авыр, кыен хәл. Кызганычка, бүгенге көндә аны актуаль дип тә була. Ялгыз яшьләр дә бар, олы яшьтәгеләр арасында да ялгызлар күп.

– Ни өчен кеше ялгызлыкка дучар була һәм ни өчен соңгы вакытта андый кешеләр арта?

– Аның сәбәбе күп, әмма, нигездә, төп сәбәп динсезлектә, ягъни Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәмәүдә. Коръәндә Аллаһы Тәгалә: «Без сезне парлап яраттык», – дигән. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.)дә: «Өйләнешегез, никахлашыгыз. Кем никахтан баш тарта, ул бездән түгел», – дигән. Икенче хәдистә: «Балалар табыгыз, күбәегез», – дип әйтә. Яшьләр, без үзебез өчен генә яшибез, тормышның бөтен ләззәтен татып каласыбыз килә, карьера ясыйсыбыз бар әле башта, дип әйтергә ярата. Күпмедер вакыт узгач, чыннан да, байлыкка да, олы дәрәҗәгә дә ирешәләр. Менә шул вакытта шайтан кешене котырта башлый да инде: «Кияүгә чыксаң, балалар үстерәсе, иреңне карыйсы була. Эшеңне дә калдырырга туры киләчәк», – ди. Аннары кызларның «ак атка атланган принц» көтү очраклары да аз түгел. Алар булачак ярларына бик югары таләпләр куя, әмма андый кешене таба гына алмыйлар. Шул рәвешле күп кенә кызлар кияүгә чыкмыйча кала да инде. Егетләр дә күп вакытта акча туплагач кына кемгә өйләнергә икән дип сайлана башлый. Әмма бу вакытта башларында, минем байлыгыма кызыгалар инде, дигән уй бөтерелә. Шул рәвешле ялгызлар сафы да арта. Парлашканнар арасында да, Европага ияреп, без әле яшьләр, безгә бала кирәкми, үзебез өчен яшик әле, дип уйлау модасы бар. Ә бит гомер бик тиз үтеп китә һәм картайган көндә бер ялгызың калырга мөмкинсең. Бәлкем, кайберәүләргә ялгыз булулары хәерлерәктер дә, чөнки яман холыклы, тәртипсез, бозык кеше белән яшәгәнче, үзе генә булу күпкә әйбәтрәктер. Хәерлесен Аллаһы Тәгалә генә белә.

– Ялгызы калган кешегә нишләргә? Аларга нинди киңәшләр бирер идегез?

– Иң беренче шуны онытмаска кирәк: ялгыз калу ул – Аллаһы Тәгаләнең сынавы. Тормышта теләсә кем ялгызы калырга мөмкин. Әмма мөселман кешесе беркайчан да ялгызы булмый! Кайда гына булсак та, Аллаһы Тәгалә безнең белән. Без аны калдырмасак, ул безне калдырмый. Фәрештәләр дә һәрвакыт безнең белән. Белмәгән кеше намазга өйрәнсә, белгәне гел укып торса, кешенең төшенкелеккә бирелергә вакыты да калмаячак. Аның һәрвакыт аралаша һәм хәлләрен белеп тора торган мөселман дуслары да күп булачак. Шуңа күрә дингә килергә кирәк. Балаларыбызны да, ялгыз калмас өчен, дөрес итеп тәрбияләсәк иде. Әти-әниләренең хәлен бөтенләй белмәүче балалар да бар. Һич югы телефоннан шалтыратырга була бит инде. Ә туганнар белән аралашмыйча тору – гөнаһ. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) дә, гомереңнең озын булуын теләсәң, туганнарыңның хәлен белешеп тор, дигән. Әгәр дә без Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәсәк, Пәйгамбәребез әйткәннәрне тыңласак, күп кенә проблемалар үзеннән-үзе юкка чыгар иде. Бу, әлбәттә, ялгыз кешеләр булмас иде дигән сүз түгел, әмма алар мин ялгыз дип кайгырышып утырмаслар иде.

Хикмәтле сүзләр

Ялгызлык – җанга сихәт алу халәте.

Ялгызлык – үзеңне чыбыркылый алырдай гадел хөкем мөнбәре.

Ялгызлык – күңелнең ялангач халәте.

Марсель Галиев

Кеше күңеле корыч булса – ялгызлык тутык булып ябышырга әзер.

Фәнис Яруллин

Картлык дигәнең дә бит ул, яши белмичә картаючылар зарланганча, ул тикле куркыныч та түгел. Ялгызлык куркыныч! Ялгызлык!

Габдрахман Минский

Гаеп үзебездә!

Бер бистәдә гади генә бер хатын-кыз яшәгән. Аның балалары, ире, туганнары булмаса да, ул бик тә яхшы күңелле һәм ярдәмчел кеше булган. Аңа ярдәм һәм киңәш сорап та бик күп кеше кергән. Ул һәр кешене дә ягымлы сүз, яхшы мөгамәлә белән каршы алган. Менә берьюлы аңа күршесе керә. Аның исә гаиләсе зур: балалар, ире, оныклар. Әмма ул нигәдер бик моңсу.

– Мин шундый ялгыз, – дип зарлана икән хатын. Балалар үсеп бетте, аларның үз тормышы. Оныкларның да үз кызыксынулары. Ирем белән икәү генә калдык хәзер. Аның белән дә элеккеге кебек үк якын түгел инде. Хәер, син мине аңлый да алмассың инде. Син бит гомер буе ялгыз, – дигән.

– Бу сүзләрдән соң хатын бераз уйлап тора да:

– Әйе, чыннан да, мин сине аңлый алмам, чөнки мин үземне беркайчан да ялгыз хис иткәнем юк. Минем әйләнә-тирәмдә бөтен дөнья булганда, ничек үземне ялгыз хис итим, ди. Без ирекле һәм бәхетле булып туабыз. Ә ялгызлыкны үзебез үк тудырабыз бит. Көн саен берберебезне аңламау, дәшмичә йөрү һәм әйтеп бетерелмәгән сүзләр аркасында иң якын кешеләребезне югалтабыз түгелме соң? Алар белән бергә яшәсәк тә, үзебезне ялгыз хис итәбез. Ә син менә тирә-ягыңа бер әйләнеп кара әле: синең янында бөтен дөнья бит! Бары аңа каршы барырга һәм ачык булырга гына кирәк!

Янымда робот-иптәш

Ялгыз кешеләр саны буенча Япония иң алдынгы урынны алып тора. Соңгы елларда монда 65 яшьтән өлкәнрәк ялгызлар саны 5 миллионга тигезләшкән. Япония ялгызлар иң күп ил булгач, биредә андый кешеләрнең тормышын җиңеләйтү өчен дә төрле уңайлыклар булдырып, яңа технологияләр уйлап табып бетергәннәр. Нәкъ менә алар өчен бу илдә азык-төлек кибетләрендә махсус рәвештә үстерелгән кечкенә яшелчәләр (бер кешелек кенә) саталар. Бу идея күпләр яшелчәләрне бүлеп ала башлагач туган. Япония инженерлары, ялгыз өлкән яшьтәге кешеләрнең тормышын берникадәр булса да җиңеләйтү өчен, махсус роботлар уйлап чыгарганнар. Робот-дуслар тәгәрмәчләрдә хәрәкәтләнәләр һәм алар һәрвакыт интернетка тоташтырылган. Алар белән рәхәтләнеп сөйләшеп утырырга була. Хуҗасы җавап бирмәсә, ул тиз арада ашыгыч ярдәм чакырта. Дөрес, әлегә иптәш-роботлар Япониядә кулланылышка кереп кенә бара. Әмма алар өлкән яшьтәге ялгызлар өчен чыннан да бер иптәш булыр иде. Һәрхәлдә, бер ялгызың утыру түгел инде...

Хроник ялгызлыктан бармы чара?

Фоат МОРТАЗИН

Качып була уттан,
Аюдан, бүредән.
Суыктан, эсседән,
Кораллы кешедән.

Качып була сәрхуш,
Угры, талаучыдан.
«Малыңмы?»,
«Җаныңмы?» –
Диеп янаучыдан.

Хроник ялгызлыктан
Бармы берәр чара?
Кайчан инде яшең
Туксан таба бара?

Нәсел-ыругыңда
Тик син генә калган
Балаң юк... Иркәңне
Аллаһ иртә алган...

Иң читен ялгызлык
Ник картлыкка кала?
Без кат-кат сораган
Тигез гомер кайда?

Чәй өстенә тукмак:
Дистә сырхау изә.
Кояш баеш якын:
Сизгер күңел сизә.

Бу хроник ялгызлык
Тәмуг утына тиң.
Дөньяда ук янгач,
Тәмугта янмам мин...

Аллаһы Тәгалә дөньяны юктан бар иткәндә барча җаннарны да яралткан һәм сорау биргән: «Әләстү бираббикүм», ягъни: «Раббыгыз кем?» Шул вакыт барча җаннар: «Син безнең Раббыбыз һәм тәрбиячебез», – дип, Аллаһны таныйлар. Шулвакыт Аллаһы Тәгалә җаннарга Үзен күрсәткән. Ничек күрсәткәне безгә мәгълүм түгел. Менә шушы җаннарны Раббыбыз «тән» дигән киемгә төреп, Җир йөзенә сынар өчен җибәргән. Җир йөзендә җаннар тән рәвешендә үзләрен һәм башка җаннарны күрәләр, әмма Аллаһны күрмиләр. Аллаһны таныган, бертөсле үк иман китергән җаннар төрлесе төрлечә гомер сөрә башлый, төрле язмышка дучар була.

НАЧАР ЯЗМЫШ ЮК

НӘСЫЙХӘТ

Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ, Татарстан Республикасының баш казые

Кайберәүләр, төшенкелеккә бирелеп: «Минем язмыш начар, мин берни дә эшли алмыйм», – дип йөри. Кайберәүләр, масаеп: «Мин барын да булдырам», – ди. Югыйсә Адәм баласы белә бит, Аллаһ теләмәсә, алдында торган ризыкны да кулың белән алып, авызыңа китерә алмыйсың һәм беркем дә синең бу халәтеңне үзгәртә алмый. Бүген: «Шифаны Аллаһтан сорагыз», – дигән өчен кайбер табибларны гаепләп чыгучылар да бар. Ул табиб та бит Аллаһ кулындагы бер инструмент, Аллаһ теләсә, аның аркылы шифа бирә, тели икән, үлемгә дучар итә. Әллә нинди данлыклы, күренекле табиблар, өшкерүчеләр, экстрасенслар бар, шифа алар кулында булса, берәү дә үлмәс иде.

Хакыйкатьтә начар язмыш та юк, Аллаһның хәерсез эше дә юк. Раббыбыз Коръәндә («Инширак» сүрәсе, 5-6 нчы аятьләр): «Фә иннә мәгәл гүсри йусра. Иннә мәгәл гүсри йусра», ягъни: «Дөреслектә, авырлыктан соң гына файдалы җиңеллек табыла», – ди.

Бер риваять бар. Берәүнең бик яхшы аты булган. Аңа бик кыйммәт бәяләр биреп сатып алырга теләүчеләр килгән. Әлеге кеше ярлы булса да, атын сатмаган. Көннәрдән бер көнне ат югалган. Кешеләр: «Кыйбатка саткан булсаң, бай булыр идең, хәзер атың да юк, акчаң да юк», – дип картны шелтәлиләр икән. Карт: «Ахыры хәерле булсын», – дигән. Бер атнадан картның аты унлап кыргый ат ияртеп кайтып кергән. Күршеләре сокланып, көнләшеп карагач, карт: «Ахырын белмисез», – дигән. Картның улы булган. Ул кыргый атларны өйрәтә башлаган. Бер төнне аттан егылып, бик нык имгәнгән. Күршеләре: «Бердәнбер малаең имгәнде бит», – дигәч тә: карт: «Ахыры хәерле булсын», – дигән. Шул елны сугыш чыгып, бар кешенең дә улларын сугышка алып киткәннәр. Картның улы янында калган. Күршеләре: «Синең улың бераз аксаклап йөрсә дә янында, ә безнекеләр юк», – дип борчылалар икән. Әнә шулай хәерсез эш булмаган кебек начар язмыш та юк.

Кайбер риваятьләрдә: дөнья яралтылгач, Аллаһ җаннарга җирне дә, җәннәтне дә күрсәткән диелә. Кайбер җаннар: «Безгә җирдән берни дә кирәк түгел, җәннәт булса җиткән», – дигәннәр. Менә шул җаннар Җир йөзендә гарип, дивана булып яшиләр йә булмаса, сабый чакта үләләр. Ә без ниләр генә әйтмибез. Аллаһны мәрхәмәтсезлектә гаепләп, көферлеккә төшәбез. Ә хакыйкатьтә, ул язмышын җаннар үзләре сайлаган. Алар ахирәттә бернинди мәшәкатьсез Аллаһның җәннәтенә керәчәкләр.

Кайбер җаннар: «Җирдә, җәннәттә ошамый», – дигәннәр. «Сезгә ни ошый соң?» – дигәч: «Йа Раббыбыз, безнең сиңа якын буласыбыз килә», – дигәннәр. Аллаһ: «Мин мохтаҗлар, кайгы-хәсрәтләргә якын булам, сез алар күргән авырлыкларга түзәрсезме?» – дип сораган. «Сиңа якын булыр өчен без бар нәрсәгә дә риза», – дигәннәр. Болар миллионлаган җаннардан берәр генә булган. Алар – пәйгамбәрләр һәм әүлияләр җаннары. Шуңа күрә дә иң күп борчумәшәкатьләр, авыру-сырхаулар пәйгамбәрләргә һәм әүлияләр язмышына төшә. Бу исә иманы зәгыйфь булган күп кенә кешеләрне көферлеккә төшерә: «Әнә гомер буе намаз укый, хәрамга да катышмый, үзенең борчумәшәкатьтән арынганы юк», – дип уйлыйлар.

Калган кешеләрнең дә язмышлары төрлечә. Раббыбыз һәркемгә дә җәннәткә керергә мөмкинлек биргән, шул ук вакытта берәү дә: «Җәһәннәм газабына эләкмим», – дип тә әйтә алмый. Бүген аракы эчеп, кеше талап, зина кылып һәм башка шундый зур гөнаһлар кылып яшәүчеләр бар. Андый кешеләр аркылы Аллаһы Тәгалә башкаларга бу эшләрнең никадәр начар икәнлеген күрсәтә. Локман Хәким: «Әдәпсезләргә карап, әдәпкә өйрәндем», – дигән.

> ***Бүген: «Шифаны Аллаһтан сорагыз», — дигән өчен кайбер табибларны гаепләп чыгучылар да бар. Ул табиб та бит Аллаһ кулындагы бер инструмент, Аллаһ теләсә, аның аркылы шифа бирә, тели икән, үлемгә дучар итә. Әллә нинди данлыклы, күренекле табиблар, өшкерүчеләр, экстрасенслар бар, шифа алар кулында булса, берәү дә үлмәс иде***

Берәүнең малае эчәргә һәм отыш уеннары уйнарга ярата икән. Әтисе тегеләй дә, болай да вәгазьләп караган, нәтиҗәсе булмаган. Үләр алдыннан улына әйткән: «Син инде мине тыңламадың, соңгы сүземне тыңла, эчсәң – даны чыккан эчкече белән эч, уйнасаң – иң атаклы уенчы белән уйна». Атасының вафатыннан соң улы иң даны чыккан эчүчене һәм отыш уеннары уйнаучы атаклы кешене эзләп киткән. Эзләп тапса, шәһәр читендә ташландык подвалда яшәүче бомжлар икән болар. Берсен – эчү, икенчесен отыш уеннары шул хәлгә җиткергән. Малай аларны күреп гыйбрәтләнгән һәм начар гадәтләрен ташлаган.

Кем генә булмасын, Раббыбыз һәркемгә тәүбәгә килергә мөмкинлек биргән. «Фуркан» сүрәсенең 70 нче аятендә Аллаһы Тәгалә: «Илләә мәң тәәбә үә әәмәнә үә гамилә гамиләң саалихәң фә үләәәикә йүбәддилүллаааһү сәййиәәтиһим хәсәнәәт...», ягъни: «Мәгәр берәү тәүбә итеп, иман китерсә һәм Коръән юлы белән изге гамәлләр кылса, әнә шундый кешеләрнең начарлыклары яхшылыкка алмаштырылыр, Аллаһ андыйларга ярлыкаучы вә рәхмәт кылучы булыр», – ди. Менә бу аять Аллаһның мәрхәмәте чиксез икәненә, бар кешегә дә тәүбәгә килеп, төзәлергә мөмкинлек бирелүенә дәлил түгелме? Кеше ярамаган эш эшләп бер гөнаһлы булса, тәүбәсен кичектереп, акылга килмичә йөреп, тагын да зуррак гөнаһка тара. Беренчедән, тәүбәгә килмичә, имансыз булып үлеп китүе бар. Икенчедән, тәүбәгә килмәү ул – гөнаһыңны инкарь итү, ягъни тәкәбберлек була.

Берәү бай икән, бу әле бәхет түгел. Байлыгына шөкрана кылмаса, тиешле зәкят, гошерләрен бирмәсә, ятимнәргә, мохтаҗларга, мәчет-мәдрәсәләргә ярдәм итмәсә, бу байлык дөньяда аның җан тынычлыгын ала, ахирәттә җәһәннәмгә алып бара. Берәү сау-сәламәт булып та, шуңа шөкрана кылмаса, гарип-горабаларга, инвалидларга ярдәм итмәсә, көчсезләрне якламаса, руза тотмаса, мәчеткә йөрмәсә, сәламәтлеге аны шулай ук тәмугка кертә.

Берәү мәчеткә йөрсә, намазлар укыса, руза тотса, әмма бу эшләре белән масайса, башкаларга кимсетеп караса, бу тәкәбберлек, хәтта изге гамәлләрен дә юкка чыгарып, аны җәһәннәмгә алып бара. Бүген безгә Аллаһның рәхмәте булып, намаз укыйбыз, мәчеткә йөрибез, ураза тотабыз икән, һәр изге гамәлебез өчен Аллаһка шөкрана кылуыбыз кирәк. Масайсак, мин булдырам, дисәк, көферлеккә төшүебез бар. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.): «Күңелендә тары бөртеге кадәр генә тәкәбберлеге булган кеше җәннәтнең исен дә сизмәс», – дигән.

Һәрбер кылган гамәлебез фәкать Аллаһ ризалыгы өчен генә булып, калебләребезне чистартырга, күңелебезне нечкәртергә һәм үзебезне түбәнчелекле тотарга ярдәм итәргә тиеш. Шулай булганда гына хак юлдан тайпылмыйча, Аллаһның җәннәтенә алып баручы гамәлләр булыр, иншә Аллаһ.

Раббыбыз адашкан, тәүфыйксызлыкта йөргәннәргә тәүбәгә килергә, туры юлны табарга, изге гамәлләр кылып та тәкәбберләнүчеләргә шул изгелекләрен югалтмаска ярдәм күрсәтеп, Үзенең җәннәтләрендә очрашуларыбызны насыйп кылса иде.

СӨМБЕЛӘ, тәреңне ташла!

Беркөн Чаллыда яшәүче Дамира апам шалтырата. «Сеңлем, синең киңәшең кирәк миңа, ни эшләргә дә белмим», – ди. Тиз арада, бөтен эшләремне ташлап, үзләренә килеп җитүемне үтенә. Апа сүзен аяк астына салып ташлап булмас, килешмәс дип, өйдәгеләрем белән киңәшләштем дә юлга да кузгалдым. Чаллыга барып, апаларга килеп керсәм, ул мескенем диванда елап утыра.

БЕЗНЕҢ ПОЧТА

Эльвина ШИҺАБЕТДИНОВА

– Нәрсә булды, апа? – дим. – Әллә берәр күңелсез хәл булдымы?

– Булды шул, – ди.

Апамның икенче никахыннан туган кызы бар. Сөмбелә исемле ул. Аның менә өченче ел инде рус егете белән очрашып йөрүе турында соңгы арада бик еш ишетергә туры килде. Апам да, барлык туганнарыбыз да аның Дима белән мәхәббәт куертуына каршы килдек. Беткәнме әллә зур шәһәрдә татар егетләре? Тик Сөмбелә генә никтер сүзләребезгә колак салырга теләмәде.

Сеңлебез әле яшь булганлыктан, аның бу рус егете белән мавыгулары үтәр дип уйладык без. Һәм шуңа да артык басым ясауны кирәк тапмадык. Бүгенгә кадәр.

Апамның әйткән сүзләреннән аяк астымдагы җирләр убылып киткән сыман булды. Сөмбеләбез Димасына ияреп чиркәүгә барган, динен алыштырган, муенына тәре аскан.

– Мин бит аны тудырып үстергән ана. Миңа әйтми генә, минем белән киңәшләшми дә нигә шундый хәл ясады икән ул, һич аңлый алмыйм. Тегесе шул кадәр дә якынмы икәнни соң үзенә? Табып үстергән анасыннан да кадерлерәкме икәнни соң?

Апамның өзгәләнүләрен күреп, җаныма урын таба алмадым. Ничек кирәк алай, тынычландыра торган дарулар эчертеп, бәхетсез ананы урынына яткырдым да, аның вакытсыз агарган чәчләреннән сыйпап, йокыга киткәнен көтә башладым. Уйларымны ишек ачылып ябылган тавышлар бүлде. Апамны уятмаска тырышып, сак кына кузгалсам да, барып чыкмады, ул йокламаган икән. Миннән дә алда, караватыннан сикереп торып, ишектән керүченең каршысына ташланды.

Сөмбелә мине күргәч каушап китте. Мин кечкенәдән кадерләп үстергән кызчыгыбызны яратып кочагыма алдым. Ул бөтен барлыгы белән куеныма сыенганнан-сыена барды, үзе бертуктаусыз: «Апам, ачуланма мине. Гафу итә күр, апам, – дип ялварды. Аннан соң, яшь сарган күзләрен тутырып миңа карады да: – Мин бүтәнчә булдыра алмадым, син булса да аңла мине», – дип, күзләремә текәлде.

Кочагымда иркәләнгән шушы кызның сүзләренә җавап таба алмый, аптырап торганда, бөтен уйларымны апамның елыйелый әйткән сүзләре бүлде. Тәре асып... Адәм көлкесе... Нәселдә булган хәл түгел бит бу!

Икенче мизгелдә, куенымдагы Сөмбелә ялт итеп атылып чыкты да, апама карамаска тырышып: «Диманы да, минем динемне дә хөрмәт итмисез икән, бүтән бу йортка кайтмаячакмын», – дип яшен тизлеге белән ишектән урамга чыгып та йөгерде.

Сөмбелә чыгып киткән кичне апамны хастаханәгә салырга туры килде. Йөрәге бу хәлләрне тагын да күтәреп торырга теләмәде, ахрысы. Тик кызы гына әнисенең хәлен белергә килеп карауны кирәк тапмады. Динен генә түгел, җанын да саткан иде, ахрысы, Сөмбеләбез.

Гыйнварда намаз вакытлары

	Иртәнге намаз	Кояш чыга	Өйлә намазы	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
3	07:42	09:12	13:02	14:36	16:23	17:53
4	07:42	09:12	13:02	14:37	16:25	17:55
5	07:41	09:11	13:02	14:39	16:26	17:56
6	07:41	09:11	13:02	14:40	16:28	17:58
7	07:40	09:10	13:02	14:41	16:29	17:59
8	07:39	09:09	13:02	14:43	16:31	18:01
9	07:39	09:09	13:02	14:44	16:32	18:02
10	07:38	09:08	13:02	14:46	16:34	18:04
11	07:37	09:07	13:02	14:47	16:35	18:05
12	07:36	09:06	13:02	14:49	16:37	18:07
13	07:35	09:05	13:02	14:50	16:39	18:09

«ШК» – кунакта

Еллар үткән саен, үзебезнең яшьлек еллары белән бергә театр артистларының яшь чаклары да хәтердә еш яңара. Студент чакларыбызда аларның сәхнәдә уйнауларына гашыйк булып йөри идек без. Әнә шундый актерларның берсе – Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге һәм СССРның Дәүләт бүләге иясе Ринат Таҗетдинов та гомер баскычының 75енчесенә җиткән икән бит. Артистның үткән юлын бераз гына булса да күздән кичерү максатыннан, аларның өйләренә юл тоттым. Ишектән керүгә үк, аларның фатирыннан җылы, якты нур бөркелә. Бу исә хуҗаларның киң күңелле, ачык йөзле булуыннандыр.

ГОМЕР СУКМАГЫННАН ЯРТЫ ГАСЫР БЕРГӘ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Гаилә архивыннан

«Бер күрүдә гашыйк булдык»

Алар белән сүзебезне дә хәтер йомгагын сүтүдән башладык. Билгеле инде, беренче мәртәбә үзенең яшьлек мәхәббәтен очратуы хакында Ринат абый сөенеп искә ала: «Без V курста укыганда Илһам Шакиров Мәскәүгә концерт белән килде. Егетләр белән шунда киттек. Шул чакта янымда утырган чибәр кызга күзем төште бит. Мин аңа бер күрүдә гашыйк булдым. Без берничә айдан укуны тәмамлап Казанга кайтып киткәч, арада бер ел буе хатлар йөрде. Әле һаман да аларны Рәисә апагыз ертмыйча саклап тота. Шәһәр кызы булгач, әти-әни каршы килмәгәе дип, туйны да Мәскәүдә генә үткәрдек. Ул башта татарча да белми иде. Шулай да авылга кайткач, туганнар яратып калды үзен. Артистлар бер-берсен санламый дигән сүз белән килешмим мин. Безнең буын тугрылыклы булды. Аерылышу дигән нәрсә уйга да кереп карамады. Талашсаң да, мода өчен генә талашасың. Кайбер гаиләләрдә бер кырын сүздән дә тавыш чыга. Гомумән, хәзерге вакытта нык ярату дигән нәрсә сизелми. Әллә нинди зур машиналарда йөреп, туйлар үткәреп өйләнешәләр дә бер елдан соң аерылышалар. Рәисә минем бәхетемә туры килгәндер. Ул гомер буе бухгалтер булып эшләсә дә, сәнгатьне яратты. Мин һаман гастрольләрдә йөргәнлектән, балаларны күбрәк ул тәрбияләде.

Рәисә ханым:

– Минем татар концертына беренче мәртәбә баруым иде. Шунда Ринатка бер күрүдә гашыйк булып куйдым. Башта Наил Дунаев сүз башлады. Аннары безне калдырып үзе китеп барды. Ринатның миңа чибәрлеге, тыйнаклыгы, кешелеклелеге ошады. Мин аннан беркайчан да көнләшмәдем. Аның эше театр икәнен яхшы аңладым. Кияүгә чыккач, авылны беренче мәртәбә күрдем. Аның әти-әнисе бик сөйкемлеләр иде. Әни кышларын үзебездә дә яшәде.

Әнә шулай бер-берсен өзелеп сөйгән бу пар гомер сукмагыннан 50 ел буе бергә атлый. Һаман да мәхәббәт хисләре сүрелмәвен аларның күз карашларыннан да аңлап була.

Алма агачыннан ерак төшми дигәндәй, Рәисә һәм Ринат Таҗетдиновлар берсеннән-берсе акыллы ике кыз үстергәннәр. Руфинә финанс-икътисад институтын тәмамлап, кандидатлык диссертациясе яклаган. Бүгенге көндә мәдәният һәм сәнгать университетында укыта. Читтән торып Мәскәүдәге театр институтында белем алган. Үзе язган фәнни китаплары да шактый. Кечеләре Айсылу геология өлкәсендә эшли. Кияүләрен дә яратып телгә ала Ринат абый. Алар оныкларының сәләтле булуына куанып яшәгәндә, 16 яшьлек Алинәнең кинәт гомере өзелүе аларны хәсрәт утына салды. Бүгенге көндә оныклары Лия – Казан дәүләт федераль университетының информатика факультетында белем ала, ә Әминә балалар бакчасына йөри.

Тормыштагы мәхәббәт сәхнәдә дә ярдәм иткән

Сәнгатьнең биек үрен яулаган артист иҗат турында сөйләшми калмый, билгеле. Заманында укырга керергә имтихан тапшырганда, 28 яшьлек артист Шәүкәт Биктимеров: «Бу егет безнең театр өчен туган», – дип юкка әйтмәгәндер. Чыннан да, Ринат Таҗетдинов гомер буе халкыбызның яраткан актеры булды. Аның «Сүнгән йолдызлар»дагы 500 мәртәбә уйнаган Надирын, «Моңлы бер җыр»дагы – Мусаны, «Ташкыннар»дагы – Мирвәлине, «Гүзәлем Әсәл»дәге Ильясны һ.б. рольләрен хәтерләмәгән кеше бармы икән? «Бирнәсез кыз»дагы Карандышев роле өчен Р.Таҗетдинов СССРның Дәүләт бүләгенә лаек була. Уйналмыйча, хыялда калган рольләре дә бар Ринат абыйның. Аңа мәхәббәт геройларын уйнарга тормышта үзенең яратуы да ярдәм итми калмаган, билгеле. Артист әйтүенчә, партнерларың да синең күңелеңә ошарга тиеш. Наилә Гәрәева белән «Гүзәлем Әсәл»дә уйнаган сәхнә бүген дә аның күз алдында. «Гомерем буе Отеллоны, Ричард III не уйнарга хыялландым мин. Заманында Марсель Сәлимҗанов аларны куярга курыкты. Артистны үстерү өчен дөнья классикасын сәхнәләштерергә кирәк. Анда уйнарга рәхәт. Әле аяк йөргәндә, баш эшләгәндә уйныйсы килә. Театрда бит төрле буын артист кирәк», – ди ул. Р.Таҗетдиновның сәхнәгә аяк басуына да ярты гасыр узып киткән. Заманында үзен укытырга чакырып та, анда бармавына үкенгән чаклары да бар актерның. 25 ел буе Театр әһелләре берлеген җитәкләү аның шактый вакытын ала.

Ринат абыйга: «Щепкинчыларның үзара дуслыгының сере нидә соң?» – дигән сорауны бирмичә кала алмадым. Аңа каршы: «Безне укытучылар бер гаилә сыман яшәргә өйрәттеләр. Мәскәүдән кайтуга, барыбыз да җыелып фатир сорап директорга кергән идек. Рәшидә апа Җиһаншина килгәч, аныСын да алдык. Без беркайчан да бер-беребезне сатмадык, бер-беребезне рәнҗетмәдек, бердәм булдык, аңлашып яшәдек», – дип җавап бирде артист.

«Сәнгатькә тугрылыклы булырга, аны яратырга, күп китап укырга кирәк», – дип, үз тәҗрибәсеннән чыгып, яшьләргә киңәшләрен дә җиткерде Ринат абый.

Әгәр язмыш үзен театр юлыннан җибәрмәсә, Ринат Таҗетдинов бүген нинди һөнәр иясе булыр иде икән соң?

Бу соравымны гына көткәндәй: «Бик җырлыйсым килә иде минем, – дип сүз башлады ул. – Тавышым да әйбәт иде. Егетләр армиягә киткәндә мине яннарына утыртып җырлаталар, гармун уйнаталар иде. 10 нчы сыйныфтан соң туп-туры консерваториягә китеп бардым. Анда укырга керү өчен нота, сольфеджио кирәклеген беркем дә әйтмәде ул чакта. Уку йортына килгәч кенә белдем. Шуннан соң театр юлыннан китәргә туры килде. Һәм ялгышмаганмын дип уйлыйм. Язмышымны театр белән бәйләмәсәм дә, юкка чыкмаган булыр идем. Без гаиләдә биш малай, бер кыз үстек. Туганнарым укытучы, табиб, химик, механик һөнәрләрен сайлады».

Электән килгән гадәт буенча Ринат абый буш вакытларында китаплардан аерылмый. Кулына сыйныфташы Мөстәкыйм бүләк иткән гармунын алып халкыбызның моңлы җырларын сузарга ярата.

Алар башка бәйрәмнәрне өйдә үткәрә, ә Яңа елны һәрвакыт олы кызлары Руфинәләрдә каршыларга гадәтләнгән. Аннары 1 гыйнварда Ринат абыйның туган көнен билгеләп үтәләр. Артист бүләкләр алырга яратмаса да, хатынына, балаларына үзе сайлаган әйберләрне биреп, аларны сөендерә. Р. Таҗетдинов театрда бөек актер булса, тормышта әнә шундый кайгыртучан, изге күңелле гаилә башлыгы.

Рәисә ханымнан алма белән карлыган бәлеше рецепты

Аның өчен катык, 1 ярым йомырка, 100 грамм май, ярты стакан шикәр комы, өч стакан он, сода салып камыр басарга да ике сәгать тотарга кирәк. Аннары камырның өчтән ике өлешен таба төбенә җәеп, өстенә туңдырылган алма белән карлыганны, шикәр комы белән май саласың да җәелгән камыр белән каплыйсың. Өстенә күкәй сөртеп пешерергә куясың.

Р.Таҗетдинов тормышыннан кызыклы хәл

– Бервакыт Елга портында Илһам Шакиров белән карбыз алып ашадык. Куллар балланып бетте. Илһамның концертка барасы бар. Кул юарга су эзләп Идел буена төшәргә булдык. Мин ярдан шикләнеп карап торганда, Илһам су читенә басып иелде дә кулын юарга кереште. Шулчак аның аягы таеп китте дә выжт итеп суга килеп төште. Муенына хәтле суда тора бу. Куркуыннан кычкырып та куйды. Ул миннән ярдәм сорый башлады. Мин аңа кулымны бирсәм, икәүләп батачагыбызны белеп торам. Аннары коткаручы да юк бит. Илһам үзен ташлап китеп бара, дип уйлаган. Шуннан соң таяк табып килдем дә тартып чыгардым үзен. Берзаман манма су булып урамнан йөгереп кайтып барабыз. Таныган кешеләр безгә аптырап, артыбыздан карап калдылар.

«Мин «Алтын Барс»ка лаек идем»

Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен хәтерлисезме? Андагы Нәҗибә Ихсанова ролен дә хәтерлисез инде алайса. Аның вакытыннан алда картайган иренә әйткән сүзе күпләрнең каната гыйбарәсенә әйләнде: «Үүлиеммм». Мин дә еш кабатларга яратам ул сүзне. Яшь җырчы Ришат ФАЗЛЫЙӘХМӘТОВ белән берничә кат әңгәмә корырга җыенгач та кабатлап алырга туры килде. Инде күптән йолдыз чире йоккан яшьләр белән аралашкан булмаган икән. Кичә-бүген генә сәхнәгә күтәрелмәсә дә, Ришат ул авыруны йоктырган булып чыкты. Хәер, «Ак шомырт та ак сирень», «Әле ярый син очрадың» кебек җырлары булган егетебез бу «бөеклектән» савыгыр да, гел дә тамашачыны матур тавышы белән сөендереп яшәр, дип нәтиҗә ясарга ашыктым.

ЙОЛДЫЗЛЫ ЮЛ

Гөлнара ҖӘЛИЛОВА

– Мари Эл Республикасы егете мин, – дип башлады сүзен Ришат. – Бәрәңге районы Назарбаш авылында туып үстем. Карт та түгел, яшь тә түгелмен – 1989 елгы. Ике абыем бар. Әти быел җәй көне үлеп китте, әнием исән-сау, Аллага шөкер. Пенсиядә.

– Җыр дөньясына ничек килдең?

– Мин көрәш белән шөгыльләнеп үстем. Беренче урыннар алмасам, абсолют батыр калганым булмаса да, бәйгеләрдән икенче-өченче урыннар белән кайта идем. Ә ул җиңел хезмәт түгел, физик көч таләп итүче өлкә. Һәм көннәрдән бер көнне микрофонның җиңелрәк икәнен аңладым... Көрәштән киттем дә документларымны Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетына илтеп тапшырдым.

– Бәхет ишелеп төшеп, Салават Фәтхетдинов укучысы да булып куйдың. Салават абыең төркемендә эшләргә үзе чакырдымы?

– Салават абый укытучы да, әти дә булды. «Синең тавышың бар, җырла», – диде. Төркемендә эшләргә теләп, мин аңа мөрәҗәгать иттем. Аның белән ике ел эшләдем. Әмма гел анда гына йөреп булмый – үземнең аерым үсәсем килде. Хәзер менә ике еллап үз иҗатымда гына.

– Салават тавышыннан гына арынып бетә алмыйсың бугай?

– Әйтәләр бит – чир китә, гадәт китми дип. Тавышы да, сүгенүе дә күчте *(көлә)*. Инде тавыш охшашлыгыннан котылып беттем, дип уйлаган идем – әле һаман калганмыни?

– Ә Салаватка охшамаган, шәхси сыйфатларың нидән гыйбарәт?

– Мин аралашучан, гади, елмаеп яшим. Менә быел әтине югалткач кына канатлар каерылды бераз, ничә яшьтә булса да, якыннарны югалту кыен. Әле ярый эшем бар, дим.

– Бу урында, әле ярый гаиләм бар, дигәне дә килешер иде үзеңә...

– Өйләнергә берничә кат барып җиттем инде мин. Ул чикне генә атлап чыгып җиткән юк. Бик тирән беренче мәхәббәт ярасы үзенекен итә, күрәсең...

– Сәхнә сине үзгәртте ме?

– Үзгәртте. Яхшы якка дип уйлыйм үзе – матур итеп сөйләшергә, үз-үзеңне культуралы тотарга.

– Берочтан «йолдыз чир»ле дә иттеме?

– Миндә андый чир юк. Үз-үземне таптым, тамашачым бар, ә «йолдызлык» йокмады. Шоу-бизнес ул бит шундый дөнья – анда нык торырга кирәк, шуңа ул дөньяда дуслар да булмый. «Исәнме» дә «сау бул» гына.

– Кемгәдер буйсынып эшләү кыен түгелме соң?

– Юк, миңа «Барс Медиа» компаниясендә эшләү бик ошый. Ул көчле коллектив. Үзем генә булсам, раскрутка, реклама өчен күпме акча, тырышлык түгәргә туры килер иде миңа. Ә болай бердәмлектә көч. Алар миңа булыша, мин аларны эшле итәм, дигәндәй.

– Кемнәрдер еллар буе көткән «Алтын Барс»ны син алырга да өлгердең инде. Мин әле сиңа иртә дип исәплим, ә син?

– Мин аңа үземне лаеклы, дип саныйм. Танылган җырларым бар, менә альбом чыкты – «Әле ярый син очрадың» дигән әлеге җыентыкка халык яраткан 16 җыр керде. Ф.Мортазин, А.Тимербаев, Р.Әсхәдуллин, З.Хәйретдинов иҗатын яратам. Мин тудырган халыкчан образны тамашачы яратып кабул итә.

– Яңа елның яңа карлары белән үзеңә ниләр телисең дә тормыштан ниләр көтәсең, Ришат?

– Тамашачы каршысында танылган булуымны, Татарстанның халык артисты булуымны телим. Дөньялар имин булып, тату гомер итик, һәркемнең хыялы чынга ашсын!

МӘСКӘҮЛӘРДӘН СӘЛАМ

Павел Буре әти була!

41 яшьлек хоккейчы **Павел Буре**, ниһаять, әти булачак. Хатыны **Алина Буре (Хәсәнова)** инде балаланың малай икәнен дә хәбәр иткән. Әлегә булачак әти-әни кайсы илдә бәби табачакларын турында тәгаенләми. Хәер, озак вакытын АКШта яшәүче пар, бөтен кешене кызык итеп, туйларын Россиядә уздырган иде инде. 10.10. 2009да Бурелар Мәскәүдә балдак алышты. Андый санны сайлаулары да гаҗәп түгел, Павел нәкъ менә 10лы саны астында чыгыш ясаучы спортчы. Алина исә Павелдан 15 яшькә кече, очраша башлаганда кызга нибары 18 яшь иде. Павел аның турында: «Ул минем кеше, шуңа да камыт кию мине бер тамчы да куркытмады», – дип әйтте ул чакта.

31 яшь, ә майка тузмаган

Декабрь ахыры Кыш бабай килү белән генә дан тотмый әле ул. Беләсегез килсә, ел ахыры безгә **Дима Билан**ның туган көнен дә алып килә. Менә бу юлы да танылган җырчы Мәскәүнең дәрәҗәле рестораннарының берсендә шәхси бәйрәмен билгеләп узган. Әмма өченче елгы юбилей тамашасы кебек үк булмаган ул. 30 яшен уздырырга Билан бөтен Мәскәү шоу-бизнес вәкилләрен җыеп бәйрәм итсә, бу юлы кунаклар саны тартып-сузып ике дистә кешене үз эченә сыйдырган. Кунаклар арасында **Юлия Волкова, Филипп Киркоров, Влад Соколовский**, дизайнер **Катя Добрякова**, «Муз-ТВ» телеканалы директоры **Арман Давлетяров** булган.

Пугачева — каймакта дүртенче

Россия каршындагы хезмәтләре өчен Ватан элитасы дип сез кемнәрне саныйсыз? Илебездә яшәүчеләрнең 64 проценты бу сораштыруда катнашкан инде. Узып киткән 2012 елда әлеге исемлек башында Россия Президенты **Владимир Путин** тора. 2011 ел белән чагыштырганда, аның рейтингы алты процентка күтәрелеп, 58 процентны тәшкил итә. Социологлар уздырган сораштыру нәтиҗәләреннән чыгып, икенче урынны 41 процент белән **Дмитрий Медведев** били. Өченче урынны 30 процент тавыш белән саклану министры **Сергей Шойгу** алып тора. Бу исемлекнең дүртенче урынына җырчы **Алла Пугачева** менеп кунаклаган. Анда – 18 процент тавыш. Телевидение алып баручысы **Андрей Малахов** – 11, җырчы **Филипп Киркоров** – 8, артист **Максим Галкин** – 6, **Николай Басков** белән **София Ротару** 5әр процент тавыш җыйган. Ватан каршында һәркем дә тигез түгел шул инде, нишләтәсең...

Сәхифәне
Гөлнара ҖӘЛИЛОВА
әзерләде

Ятим диеп какмагыз...



Майк Тайсон



Эдди Мерфи

ОКЕАН АРТЫ

Данте Алигьери, Иоганн Себастьян Бах, Жан-Жак Руссо кебек атаклы шәхесләребезнең тәрбиягә алып үстерелгән балалар булуы турында сез әле белмәгән дә булгансыздыр. Асрамага бала алсаң, авызың тулы кан булыр, диючеләр табылса да, кеше баласын җанытәне белән яратып үстерүче олы җаннар да бар ул. Кемдер исә ата-ана назыннан мәхрүм булып үссә дә, югалып калмый, дөньякүләм билгеле шәхескә әверелергә мөмкин. Мисалга, Югославиянең президенты **Иосип Броз Тито**, АКШ президентлары булган **Эндрю Джексон** һәм **Джеральд Форд**, шулай ук заманында АКШның беренче ледие булган **Элеонора Рузвельт** бала вакытта ук ятим калган кешеләр. Гай Юлий Цезарь уллыкка алган **Август** исә Рим императоры булып җитлегә.

Модельер **Коко Шанель**, режиссер **Франсуа Трюффо**, актерлар – **Джек Николсон, Мэрилин Монро, Эдди Мерфи, Пирс Броснан, Рэй Лиотта, Малькольм Девид Келли**лар исә ата-аналарыннан ятим калып, туганнарында тәрбияләнеп үскән шәхесләр. Уллыкта-кызлыкта үскән даһилар исемлеген дәвам итсәк, режиссерлар **Гай Ричи** һәм **Стивен Андерсон**, боксчы **Майк Тайсон**, скрипкачы **Ванесса Мэй**, Apple компаниясенә нигез салган **Стив Джобс**ны атап була. Танылган язучылар арасында исә **Герман Мелвил, Джозеф Конрад, Эдгар Алан По, Трумэн Капоте** һәм **Эли Визельләр** балачакларында әти-әнидән ятим калган балалар.

Муенга чорналган еланнан түгел, куенга кергән еланнан курык.

Бибәл Норел

ЕЛАН ЕЛЫ

(2013 елга шаян-астрологик фараз)

Яңа елга аяк бастык, җәмәгать. Алда безне ниләр көтә, Елан елы ни-нәрсәләр вәгъдә итә? Быел кемнәргә бәхет күктән ишелеп төшәр яисә кайсыларыбыз байлыкка чыдаша алмыйча интегер икән? Ат, Үгез, Күсе, Дуңгыз, Аждаһа, Сарык, Әтәч, Маймыл, Юлбарыс, Куян, Эт елларында туганнарга Еланның мөнәсәбәте нинди булыр? Мәрхәмәтлелек күрсәтерме ул аларга? Әйтик, мәсәлән, гаилә, мәхәббәт, саулык-сәламәтлек, финанс мәсьәләсендә. Җә, әйтегез, күпләрне борчыган әлеге сорауларга кем дә булса ачыклык кертә аламы?

Ләбиб ЛЕРОН

Атаклы тел белчеге вә мөтәгалим, бик күп антипопуляр академикларыбызның, үз өлкәсендә профан профессорларыбызның, фәһемсез фән докторларыбызның мәгълүмати остазы һәм мәгънәви киңәшчесе Габделмокыт ага Пәчиев әйтмешли, сүзнең алтын мөгезеннән эләктереп, үз соравыма үзем җавабын да бирим әле: ачыклык кертә алучы андый иптәш бар. Җөмһүриятебез башкаласында гаять тыйнак, артык җыйнак, шул ук вакытта, үтә зиһенле, тирән белемле, салкын акыллы, кайнар йөрәкле, киң эрудицияле, югары зәвыклы, сабыр холыклы, сизгер күңелле, күркәм кыяфәтле бер астролог яши. Мактанмыйча, сабырсызланмыйча һәм әрсезләнмичә генә әйткәндә, алдан санап үтелгән уңай сыйфатларга чынлап та ия булган ул иптәш-әфәнде мин фәкыйрегез була инде.

Кереш сүзем озын булды, гаеп итмәссез, шуңа күрә, фаразлавымны кыска тотарга тырышырмын. **Ат елында**, икенчеләй әйтсәк, җылкы җылында туган егет-җилән белән кыз-кыркын быел да бөтенләй тугарылып бетәр, нужа камытын кигән ир Атлар да, арбага ныклап җигелгән хатын Атлар да Елан елында гаилә йөген бердәй тигез дәрәҗәдә тартыр. **Үгез елында** туган яшь җилкенчәкләрне дә быел тәртә арасына кертеп булмас. Ир-егетләрнең бер ише үзләрен ел буе мир үгезе итеп хис итәр, хатын-кызларның күбесе исә, шул үгезләргә мөгез кую эше белән мәшгуль булыр. **Күсе елында** туганнар өчен Елан елы уңыш китерер: гаилә җанлы Күселәр, кайда нәрсә күрсә, шуны өйгә эләктереп кайтыр. Тамаклары тук, өсләре бөтен булган Күселәрнең гаиләләрендә ел дәвамында гармония тантана итәр. **Эт елында** дөньяга килгәннәр, ниһаять, быел әллә ни этләнмәс. Ошбу Елан елында аларның бәйдән ычкынган чаклары еш булыр. Әмма гаиләдә тәртип сакланыр, суыткычларда, туңдыргычларда сөяк-санак мул булыр, ирле-хатынлы Этләрнең бер-берсенә өрүләре сирәк күренешкә әйләнер. Тумышлары **Сарык елына** туры килгәннәр быел, китап укуга һәвәс булып, Тукайның «Шүрәлесе»н, Такташның «Мокамай» әсәрен, Кутуйның «Рөстәм маҗаралары»н, Туфанның «Юкмыш бабай» әкиятен, Батулланың «Тычкан баласы Чикыл»-ын ятлап, якыннарын таң калдырыр. **Юлбарыс елында** туганнар быел да, масаеп, башларын горур тотып яшәр. Саклану турында онытып җибәргән кайбер Үгезләргә, Сарыкларга, Атларга һәм Куяннарга Юлбарысның көтмәгәндә һөҗүм итүе ихтимал, сак булыгыз! **Куян елында** туучыларга Елан елында куркыныч янамый. Елан авызына керергә куяннар үзләре атлыгып тормаса, әлбәттә. Быел барча Куянга да тумыштан ук килгән курку хисеннән арыну зарур. Йөрәк авыруыннан интеккән Куянга исә, суга барырга ярый, әмма сулга йөрергә киңәш ителми. **Әтәч елында** дөньяда пәйда булганнарның кайберләре быел да әтәчләнеп, хатыннары яисә ирләре күп булуына масаеп яшәр. Башкаларга алардан көнләшергә кирәкми. Булдыралсагыз, үзегез дә шулай гомер итәргә тырышып карагыз. Булдыралмасагыз, ничу көнләшергә! Бер иш Әтәчләрне ялкаулык белән йокы басар. Шуңа күрә, алар, таң вакыты җитүгә карамастан, атылып торырга ашыкмас, артист халкы сыман, төш авышкач кына ятактан кузгалырга маташыр. **Маймыл елында** туганнарга быел маймыллланудан тыелырга, айга кимендә бер мәртәбә зоопаркка яисә циркка барырга, макака, шимпанзе, горилла, орангутанг ише маймылларның кыланмышыннан гыйбрәт алып кайтырга киңәш ителә. **Аждаһа елында** дөньяга аваз салучылар әүвәлгечә авызларыннан ут чәчеп гомер итәр. «Бер баш яхшы, өч баш тагы да шәп!» дигән шигарь нәкь менә аларга туры килә. Моңарчы: «Хатын түгел, аждаһа!» – дип яшәгән ирләргә быел хатыннарның: «Ир түгел син, дуңгыз!» – дип җавап бирүе ешаерга мөмкин. Дуңгыз дигәннән... **Дуңгыз елында** туган мөселманнар быел хәрам ризыктан бөтенләй баш тартачак. Андыйлар Елан елында аерым пачутта булачак. **Елан елында** туганнар, аеруча хатын-кызлар, быел кадер-хөрмәткә тиенеп яшәячәк. Актаныш төбәгендә яшәгән Кобра (Көбрә) исемле хатыннарга аптекадан елан агуы сатып алган чакта ун процент ташлама ясалачак. Сүз уңаеннан, елан агуының дәвалау үзлеге, шулай ук аның авырткан урынга тәэсир итү көче Елан елында бермә-бер артачак.

Кыскасы, Елан елында һәркемгә елмаеп-көлеп кенә яшәргә язсын!

ЭПИГРАММА

Х. ФАЛИ
(Фаил Шәфигуллин)

Зөлфәткә

– Дан юк, Зөлфәт.
– Шигырьләр яз.
– Сан юк, Зөлфәт.
– Шәп җырлар яз.
– Ял юк, Зөлфәт.
– Куроргта яз.
– Мал юк, Зөлфәт.
– Либретто яз.

(Язучыларның «Тынгысыз каләм» дигән дивар газетасыннан, 1974.)

Ләбиб ЛЕРОН шаржы

ИКЕ РОБАГЫЙ

Ләбиб ЛЕРОН

– Синең өчен мәңге утка кермим мин!
Синең өчен мәңге суга кермим мин! –
Дип ярсыгач, ялгыш өстәп куйды ир:
– Синең өчен... лутчы... «сулга» йөрим мин!

Һәр иртәне эчкән нәрсәм – яшел чәй,
Ашаганым – җиләк-җимеш, яшелчә, –
Дип алдадым үземне һәм сезне дә...
Ходай күпме биргән – шуны яшикче!

Туган көннәрен гел истә тотыйк,
Барчасын да, әйдә, бергә котлыйк!

3 (1953) – **Мөхәммәт МИРЗА** (Илфак Ибраһимов), шагыйрь.
4 (1947) – **Разил ВӘЛИЕВ,** шагыйрь, прозаик, драматург.
5 (1935) – **Әсгать САЛАХ,** прозаик, журналист.
8 (1942) – **Нәкыйп КАШТАН,** шагыйрь, прозаик.

Сәхифәне Ләбиб ЛЕРОН әзерләде

Кызыклы ракурс

Фотолар Л.ЛЕРОН архивыннан алынды

Ашадык-эчтек, сурәткә төштек...
Батуллада кунакта: алгы рәттә (сулдан уңга) – Батулла, Рәниф Шәрипов, Байбулат Батуллин, Ләбиб Лерон, арткы рәттә – Мөхәммәт Мирза, Сәйруз Батуллин, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Шәүкәт Гаделша.

ЭКСПРОМТ

Разил ВӘЛИЕВ

Карадым мин
Сабантуйда
Татар-башкорт көрәшен.
Татар, башкорт
хәлдән тайды,
Өстен чыкты керәшен.

Өч мәзәк

Дошманнарым — үз илемдә

1985 елның 19 июнендә Разил Вәлиевне Әфганстанга озатырга берничә язучы вокзалга бара. Саубуллашыр алдыннан кемдер әйтеп куя:

– Разил, син Әфганстанда сак бул! Анда дошманнар күп, исән-сау кайт!

– Әфганстанда минем дошманнарым юк! – ди Разил. – Казанда кала минем дошманнарым. Сез миңа үз ватанымда сак булырга кушыгыз!

Бер атна ач торып

Разил Вәлиев татар халкының мәнфәгатьләренә гел-гел каршы килеп сөйли торган халык депутаты Мәсгут Хафизовка болай дигән:

– Минем әби синнән бик көнләшә!

– Ни өчен? – дип сораган Мәсгут Хафизов.

– Әби әйтә: теге сакаллы малаегыз бер атна ач торып депутат булды, алтмыш ел ураза тотып та мине сайламадылар, ди.

Хатынның файдасы

Язучыларның Пицундадагы (Абхазия) иҗат йортында айга якын яшәп кайткан Разил Вәлиевтән сораганнар:

– Җә, Разил дус, әйт әле, Кара диңгезгә хатын белән баруның файдасы бармы? – дигәннәр.

– Бар! – дигән Разил. – Хатының белән барсаң, роман язарсың, ялгыз барсаң, юлдан язарсың!

(Батулланың «Тузга язмаган хәлләр» китабыннан.)

ТӨКЛЕ АЯГЫҢ БЕЛӘН, ЕЛАН ЕЛЫ

ЙОЛДЫЗНАМӘ

Менә тагын бер ел артта калды. Аллага тапшырып, яңасына аяк бастык. Кытай календаре буенча бу ел кара су Еланы елы. Ә инде еланның акыллылык символы булып торуын һәркем белә. Димәк, Яңа 2013 ел, ягъни Елан елы барлык зодиак билгеләренә дә интеллектуаль эшчәнлектә уңыш, гадел карарлар кабул итү, акыллы эш-гамәлләр вәгъдә итә.

КУЧКАР
(21.03-20.04)

Елан елында сезгә эш урынын алмаштырырга яки бизнесыгызны яңача оештырырга туры килмәгәе. Гаиләле кучкарлар яшәү урынын алмаштырырга мөмкин. Намус белән тапкан акчага яшәүчеләргә, җиңел акча яратмаучыларга елан аеруча ягымлылык күрсәтер. Шулай ук фән һәм мәгариф юнәлешендә эшләүчеләрне дә үз итәр. Елан кучкарларга горур булмаска, кешеләр белән күбрәк аралашырга, үзегез өчен авыр саналган эшкә дә алынырга киңәш итә. Елның беренче яртысында тормыш иптәшегезгә артык зур таләпләр кую, аны гел тәнкыйтьләп тору аркасында гаиләдә тынычлык югалыр. Гыйнвар, ноябрь, декабрь – гаилә кору турындагы карарга килү өчен уңайлы чор.

ҮГЕЗБОЗАУ
(21.04-20.05)

Иҗади һөнәр ияләре: актерлар, җырчылар, музыкантлар һәм рәссамнар өчен ел уңышлы булачак. Аларның сәләтен күреп алачаклар. Гыйнвар-февраль айларында максатларыгызга ирешү мөмкинлеге туар. Профессиональ өлкәдәге үсеш адымнарын тыныч, тавышсыз гына, планнарыгызны әйләнә-тирәдәгеләр белән бүлешмичә ясагыз. Хезмәттәшләрегезгә өстәмә акча эшләвегез турында сөйләмәгез, юкса алар белән мөнәсәбәтләрегез бозылырга мөмкин. Яз айлары романтика һәм күңелле очрашуларга бай күренә. Елның икенче яртысында шәхси тормыштагы вакыйгалар алга таба мөнәсәбәтләрне сакларга кирәкме икәнлеген күрсәтер. Очрашып йөргән кешегезнең хисләре көчле булмаганда мөнәсәбәтләрне өзү хәерлерәк булыр. Урамдагы очраклы яки интернеттагы танышулардан сак булыгыз. Югыйсә проблемаларга һәм күңелсез вакыйгаларга тап булуыгыз ихтимал. Гыйнвар, май, август һәм сентябрь гаилә кору өчен уңышлы чор. Акча белән бәйле проблемалар да булмый калмас.

ИГЕЗӘКЛӘР
(21.05-21.06)

Ел дәвамында гаиләгез, дусларыгызның ярдәмен-игътибарын тоеп яшәрсез. Бу елда аралашу даирәгез тараячак, аның каравы көнчел һәм ихлас булмаганнардан арынырсыз. Финанс планында ел көтелмәгәнчә булыр. Чыгымнарга игътибарлы булыгыз, артык акчагызны саклагыз. Теләгегез булганда әйбәт эшкә урнашуыгыз бар, анда яхшы гына уңышларга ирешерсез. Шәхси эш ачу өчен дә кулай ел. Әмма бизнесны гадел юллар белән генә алып барырга тырышыгыз. Сезнең өчен иң проблемалы айлар: март, май һәм июнь. Аның каравы март белән июнь ае мәхәббәт өлкәсендә уңышлы булыр.

КЫСЛА
(22.06-21.07)

Ел ахырында күпләр берничә ел хыялланган яңа урында яши башлар. Февраль һәм март айларында сәламәтлегегезгә аеруча игътибарлылык сорала. Тормыш иптәшегезнең сәламәтлеге дә борчып тормагае. Гаилә бәхетеннән ерак булганнар чын мәхәббәтләрен табар. Ел «Бер генә көн дә мәхәббәтсез булмас!» лозунгы астында узмагае әле. Яңа танышыгызга күңелегездәге бөтен нәрсәне дә сөйләргә ашыкмагыз. Иң элек аңа ышанып буламы икәнлекне тикшерегез. Гыйнвардан алып апрельгә кадәр сезнең карьера ясау мөмкинлеге бар. Әмма ел ахырында хуҗагыз белән конфликтка керүдән сакланыгыз. Елның беренче яртысында сездән хезмәттәшләрегезнең мәкерле казынулары, интригаларына түземле булу сорала. Акчаны кысып тоткан очракта йортыгызга күп кенә нәрсәләр сатып алу җае чыгар. Хәтта яшәү шартларын яхшырта, ремонт ясый алырсыз.

АРЫСЛАН
(22.07-23.08)

Тәвәккәл адымнар ясарга туры килер. Финанс ягыннан бернинди дә проблемалар булмаячак. Кышкы айларда сездән гадел кешене ялганчыдан аера белү сәләте сорала. Бу елда карьера үсешенә көч куюдан һәм хезмәт батырлыклары эшләүдән мәгънә юк. Ул өлкәдә әллә ни яхшы нәтиҗәләр күренми, аның каравы нервларыгызны гына туздырырсыз. Ел үз эшен башларга теләүчеләр өчен хәерһахлы булыр. Елның беренче яртысы мәхәббәт романнарында уңыш китерер. Гаиләле кешеләрне тормыш шартлары яхшы гына сынарга мөмкин. Әмма апрель ахырларына алар әллә ни проблемалы да кебек күренми башлар. Йолдызлар гаилә өчен җаваплылыкны арттырырга, гаиләдәге мөнәсәбәтләрне ныгытырга киңәш итә. Тормышыгызны бәйрәм итәргә тырышыгыз. Бәхет һәм күңел ачуны башка вакытка калдырмагыз: бүген үк сөенеч диңгезендә йөзегез. Без бит каралама язмыйбыз – яшибез.

КЫЗ
(24.08-22.09)

Дәүләт хезмәтендә эшләүчеләргә карьера ясау мөмкинлеге туар. Җитәкче урыннарда эшләүчеләргә ел бигрәк тә нәтиҗәле булырга охшаган. Гыйнвар-март айларында вакытыгызны һәм көчегезне бары эшкә генә юнәлтегез. Нәтиҗәсе озак көттермәс: эштә яхшы гына күрсәткечләргә ия булырсыз. Әлеге йолдызлык ияләре үзләренең керемнәреннән аеруча канәгать булыр. Гыйнвардан мартка кадәр гаиләдә киеренкелек хөкем сөрер. Җитди мөнәсәбәтләр өчен уңыш сере: мөмкин кадәр күбрәк романтика, игътибар, илтифатлылык. Боларга тагын бер-береңә карата сабырлык, үз сүзеңдә тору һәм җаваплылык хисен дә өстәгез. Елның беренче яртысында сулыш күнегүләрен үзләштерегез. Умыртка баганасы сәламәтлеге турында кайгыртыгыз.

ҮЛЧӘҮ
(23.09-23.10)

Елның беренче ярты елы уңышлы булмаса, борчылырга кирәкми. Июль аеннан уңыш сезгә дә елмаерга тора. Финанс өлкәсендәге тотрыксызлык гаиләгездә проблемалар тудырырга мөмкин. Кредит рәсмиләштермәвегез, бурычка акча алмавыгыз хәерле булыр. Профессиональ яктан үсү мөмкинлекләре июнь аеннан соң барлыкка килер. Март-апрель, июнь һәм сентябрь айлары романтик очрашуларга бай булырга охшаган. Июль-августта һәм декабрьдә мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерү турындагы сөйләшүләр уңай нәтиҗә бирер. Бу елда һавадан бүләк көтмәгез, барысына да үз көчегез белән генә ирешерсез. Гаилә корып биш ел һәм аннан да күбрәк яшәүчеләргә бигрәк тә авыр булачак. Сезнең гаиләдә каршылыклар болай да күп күзәтелгәнгә, үзегезнең дөреслегегезне исбатлау авыррак булмагае.

ЧАЯН
(24.10-22.11)

Ел каршылыклы булырга охшаган. Якыннарыгыз белән мөнәсәбәтләр дә ышанычсыз кебек. Иң кирәкле вакытта үзегез генә калып, үз ярдәмегезгә генә таянырга кала. Февраль-март, июньиюль, октябрь-ноябрьдә бурычка акча алу, мөһим килешүләргә кул куюдан тыелып торыгыз. Яз көне коллектив эчендәге вакыйгалар кемнең кем булуын күрсәтер. Җитди һәм артык дөрес булуыгыз партнерларыгыз белән мөнәсәбәтләрдә романтикага урын калдырмас. Яз айлары хисләрнең ныклыгын тикшерү, биргән вәгъдәләрнең көчен сынау вакыты булып тора. Ялгызлар үзләренең идеалларын табар. Бер уйламаган кешеләр мәхәббәтләрен белдерер. Сәламәтлегезгә килгәндә, бу елда үзегезне сакларга кирәк. Елның беренче яртысында егылып имгәнүләрдән сакланыгыз.

УКЧЫ
(23.11-22.12)

Укчыларның күңелсезләнеп утырырга вакытлары юк. Аларны актив һәм романтик ел көтә. Йолдызлар мәхәббәт өлкәсендәге көтелмәгән вакыйгалар дулкынын гыйнвар аеннан ук вәгъдә итә. Ялгызлар үз бәхетләрен ел башыннан ук эзли башласын. Бу елда керемнәр бары тик тырышлыкка гына бәйле булачак. Шуңа да узган елга караганда азрак булыр дип көтелә. Апрель-май айлары яңа эшкә керешү өчен уңай чор. Ерак сәфәргә чыгу мөмкинлеге туар. Елан елында мөһим карарларны, җаваплы эшләрне үзегез генә кабул итү һәм башкару отышлы булыр. Якын-тирәгездәге берәү хыялларыгызны гамәлгә ашырырга булышыр. Яман гадәтләрдән арынырга тырышыгыз.

КӘҖӘМӨГЕЗ
(23.12-20.01)

Интуициягез аркасында мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмыйча, матди хәлегезне яхшырта һәм файдалы кешеләр белән мөнәсәбәтләр урнаштыра алырсыз. Яраткан эшегез яхшы кәеф һәм сөенеч кенә китерәчәк. Хуҗагыз сезгә иң мөһим эшләрне генә ышанып тапшырыр. Шуңа да эш урынында абруегыз күтәрелү мөмкинлеге зур. Фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләргә ел аеруча уңышлы булырга охшап тора. Февраль, март һәм октябрь айларында керемнәрегез сөендерерлек булыр. Гыйнвар һәм апрель айларында башыгызны югалтыр дәрәҗәдә гашыйк булып куюыгыз бар. Ялгыз кәҗәмөгезләр, ниһаять, үз мәхәббәтләрен табар. Әгәр дә алар әлегә кадәр үзләренең идеалларын таба алмаган яки артык таләпчән булганнар икән, бу елда үз кешеләрен табарлар.

СУКОЯР
(21.01-19.02)

Елның беренче ярты елы бәхет һәм уңыш эмблемасы астында узар. Ел шәхси мөнәсәбәтләрдә романтика, көтелмәгән бүләкләр вәгъдә итә. Көз уртасында шәхси тормышта кара полоса көтелә. Яраткан кешегезнең хыянәтен кичерергәме-юкмы, анысын үзегез хәл итегез. Үзләренә ошамаган эштә хезмәт куючылар, ниһаять, күңелләренә ятыш булганын табар. Февральдән алып июльгә кадәр хуҗагыз белән конфликтка керү куркынычы бар. Еллар буе «эшләп алган» абруегызны үзегез үк җимерергә мөмкинсез. Хуҗагызга эш белән кызыксынуыгызны, яңа эшчәнлеккә алынырга әзер булуыгызны күрсәтергә тырышыгыз. Йолдызлар акча белән бәйле бөтен нәрсәгә дә игътибарлы булырга киңәш итә.

БАЛЫК
(20.02-20.03)

Бу елда балыкларга беренче урынга эшне түгел, ә шәхси тормышны куярга киңәш ителә. Артык эшкә бирелеп, язмышыгызны кулдан ычкындыру куркынычы бар. Финанс мәсьәләсенә килгәндә, ул узган елга караганда күпкә яхшырак булыр. Акчаны күбрәк эшләү теләге март-апрель айларында өстәмә керем чыганагы эзләүгә этәрер. Июльдә үзегезнең зуррак җаваплылыкка алынуыгызга әзер булуыгызны танып, хуҗагызга шуны белгертерсез. Октябрьдә профессиональ абруегызны күтәрү мөмкинлеге туар. Бу елда үзегезне ничек хис итүегез турыдан-туры үзегезне ничек яратуыгызга бәйле булыр.



КАЙСЫГЫЗНЫҢ КУЛЫ КАНЛЫ?

Килеп җиттек, җәмәгать! Һәр яктан мактаулы саналган, уңган-булган кешеләре белән дан тоткан Балтач районының саф татар авылы Нөнәгәрдә күптән түгел генә булган фаҗигане күз алдымда тотып әйтәм бу сүзләрне.

ФАҖИГА

Энже ЯКУПОВА

Ул көнне Нөнәгәр авылы халкы шушындый коточкыч хәбәр ишетербез дип уйлап та карамагандыр, мөгаен. Авылның хөрмәтле кешесе, гөнаһсыз ак әбисе Маһитап Нәбиеваны үз йортында вәхшиләрчә үтереп чыкканнар! Акылга сыймаслык бу хәлгә ышанырга да, ышанмаска да белмиләр. Ләкин яман хәбәр чын булып чыга.

Авылда Маһитап әбекәйне яратып күпләр аны Миңнур дип йөрткәннәр. Шушында яшәгән, тормыш көткән, балалар табып баккан ак әби, гомеренең соңгы минутлары шулай өзелер дип, мөгаен, уйлап та бакмагандыр. Башка өлкәннәр кебек үк, гомере азагынача шушы нигезендә бәхетле яшәргә хыяллангандыр.

Хуҗасын югалтканнан соң җансыз калган матур өйдә әлегә Маһитап әбинең кызы Раушания апа тора. Аның күңел халәтен бер нинди сүзләр белән дә аңлатып бетереп булмый. Шушы кайгыга түзеп, аны күтәреп, шуның белән яшәргә дә кирәк бит аңа!

«Әниемә, исән булса, шушы көннәрдә җитмеш тугыз яшь тулган булыр иде, – ди ул, авыр сулап. – Без – җиде баласы (беребез вафат), төрлебез төрле җирдә яшибез. Кайсыбыз ерак Себердә, кайсыбыз Азнакайда, беребез Әлмәттә, икенчебез Менделеевскида гомер кичерәбез. Шуңа да атна саен әни янына кайтып йөри алмадык. Шулай да җай чыккан саен аның янына ашыга, телефоннан көненә өчәр мәртәбә шалтырата идем.

Ул көнне дә телефоннан әнигә шалтыраттым. Җавап бирүче юк кына бит. Шулай берничә мәртәбә җыеп караганнан соң, күңелем тынычлыгын югалтты. Ашыга-ашыга, күршеләремнең телефон номерын җыйдым. «Зинһар, әнине генә карап чыгыгыз, авырып, берәр җирдә егылып ятмыймы икән, кан басымы белән тилмерә иде», – дип үтендем. Күрше хатыны тиз генә йортыбызга кереп чыкты да миңа шалтырата: «Раушания, өй ишегендә йозак эленеп тора, әниегез бер җирдә дә күренми», – ди. Аның шул сүзләрен ишеткәч, йөрәкләрем әллә нишләп китте. – «И Ходаем, үтереп чыгып китмәгәннәрдер бит инде?» – дип кычкырдым. Борчылуым да юкка түгел иде. Әниебез бит урамга, кибетләргә чыгып, өйне ташлап китеп йөрмәде.

Минем сүзләремне ишетеп, үзе дә куркып калган күрше хатыны авылда яшәүче туганыбыз Рауза апаның кызын чакыртып алган. Шулай да өйгә керергә курыкканнар». Тәрәзә янындагы утыргыч янына килеп, шуңа басып өй эченә күз салган ике хатын тиз арада янә Раушания апага шалтыраткан. «Раушания, әби чынлап та идәндә ята бит!» – дигән сүзләрне ишетүгә үк, Раушания апаның күңеле олы фаҗига булганын аңлап алган.

– Әнине җидесе көнне, төштән соң үле килеш таптылар, – дип елый Раушания апа. – Ә суд-медицина тикшерүе аның алдагы көнне үк үтерелүен ачыклады. Бер көн буе шунда, идәндә яткан әни. Тиз генә тапмасыннар диптер инде, үтерүче йортны тыштан йозак белән эләктереп киткән. Мөгаен, бу хәлләр кичен булгандыр, чөнки әни ишеген дә бикләмәгән булган. Үтерүче үзе өйгә килеп кергән. Аңарчы өй түрендәге телефон чыбыкларын өзеп аткан. Әни диванда утырган булган, ахрысы. Бәлки ул, мескенем, нәрсә булганын аңышмыйча да калгандыр. Теге явыз бар көченә башына балта-лом белән бәргәләгән, хәтта баш капкачлары батып кергән, тәрәзәләргә кадәр әниемнең каннары чәчрәгән иде. Өйдә бөтен җир, сандыкларга кадәр актарылган. Әнинең балдаклары югалган. Күпмедер акчасы да урлангандыр дип уйлыйм, төгәл санын әйтә алмыйм.

Фото бизәү өчен бирелә

> ***Бу хәлләр кичен булгандыр, чөнки әни ишеген дә бикләмәгән булган. Үтерүче үзе өйгә килеп кергән. Аңарчы өй түрендәге телефон чыбыкларын өзеп аткан. Әни диванда утырган булган, ахрысы. Бәлки ул, мескенем, нәрсә булганын аңышмыйча да калгандыр***

Бу фаҗига бөтен районны аякка бастыра. Полиция килеп җитә, тикшерү эшләре башлана.

Шул көнне генә бертуган энем әни яныннан кайтып китте, – дип сөйли Раушания апа. «Ул үтермәдеме икән?» – дип хәтта аннан да шикләнделәр. Ләкин әниемнең аны озатуын күрүчеләр бар. Үзем дә, ул көнне әнигә шалтыраткач: «Энемнәр нишли?» – дип сорадым. Моңа каршы әнием: «Такси килеп алып китте, ике сәгатьләп вакыт үтте инде киткәннәренә», – дип җавап бирде. Энемнәр кайтышлый аның хатынының туган ягына, Полянга да сугылырга тиешләр иде. Ә аларда телефон тотмый. Әни белән сөйләшүгә үк энемә шалтыраттым һәм недоступен дигән сүзләрне ишетеп, аларның кайтып җиткәннәренә төшендем.

Берничә көн үткәч, әбине үтерүдә шикләнеп, авылда яшәүче ике егет – Рафис белән Илгиз кулга алына. Соңрак, читтән килеп биредә яшәүче тагын бер хатын-кызга шик төшә. Озакламый Илгизне кире авылына кайтаралар. Теге хатын-кыз да кулга алынмый. Ә менә Рафис шул көннән бирле ябылуда. Рафисның әнисе Гөлҗиһан апа үзен кая куярга да белми. Шушы вакыт эчендә тәмам бетерешкән ул, улын кызганудан елый да елый.

– Ул көнне көне буе улым белән бакчада тирес түктек. Янымнан бер дә китмәде. Аны нәрсә өчен кулга алганнарын аңлый алмый тилмерәм. Яшермим, салгалады. Шуның аркасындадыр инде, тикшерүчеләргә дә: «Әбине мин үтердем», – дигән. Күңелем моның чынлыгына һич тә ышанмый. Ул бик мәрхәмәтле бала иде, тавышланып йөргәне, кеше әйберенә кызыкканы булмады. Балтачтан улымны Казанга җибәрделәр. Минем анда барып йөрергә хәлем дә юк, балама ризыклар да илтә алмыйм, – дип уфтана ул.

Һәр ана өчен үз баласыннан да яхшысы юктыр ул дисәләр дә, утыз тугыз яшьлек Рафис турында бер генә кешедән дә начар фикер ишетмәдем. Кемнән генә сорасам да: «Юк, булуы мөмкин түгел, Рафис бик нечкә күңелле, миһербанлы егет. Иясез песиләргә кадәр алып кереп, өйләрендә ашатып чыгара иде. Авылдагы һәр кешенең сүзенә колак сала, нинди генә йомыш белән килсәләр дә, кире борып чыгармый, ярдәм итә иде», – диләр. Җәйге корылык вакытында, кешеләр суга тилмергән вакытта, аты белән кеше саен су ташыган, авырсынмаган. Нахакка эләгеп, кеше хатасы өчен генә харап булмаса ярар иде шушы егет, дип тели Нөнәгәр халкы.

Маһитап әбинең кызы Раушания апа да Рафисның үзе генә шушындый кансызлык кыла алуына шикләнеп карый. «Берничә кеше булгандыр алар, бер генә кеше болай кылана алмас. Нинди хайванның кулы барды икән әниемнең гомерен өзәргә?» – дип үрсәләнә ул.

«Әни янына берничә көннән ялга кайтырга тиеш идем. Ай буе янында булырмын, ярдәм итәрмен, бергәләп күңелле булыр дип хыялландым. Әни дә, үләсен сизгән кебек, соңгы сөйләшкәндә: «Кызым, бер-ике көн алданрак кайт инде», – дип кат-кат кабатлады. Алданрак кайта алмадым шул, шунысы бик үкенечтә калды», – дип өзгәләнә хатын.

Әй, гомер диген син. Балаларын, якыннарын гомерлек хәсрәткә салып киткән Маһитап әбинең кулыннан дини китаплары да төшмәгән бит. Шушындый иманлы, саф күңелле кешенең гомерен кыярга нинди оятсызының кулы күтәрелде икән? Моны Нөнәгәр авылы халкы һич тә аңлый алмый.

Сүз уңаеннан. *Әлеге вакыйга булып озак та үтмәде, күрше Чутай авылында улының газиз әтисе гомерен өзүе турында хәбәр килеп иреште. Мондый хәлләр, кызганычка, авыл җирендә дә киң колач җәя башлады. Аллага тапшырдык...*

Баласы өчен еламаган көне юк

Бу дөньяда җан газабыннан да авыр нәрсә юктыр ул. Саимә инде ничә еллар буе әнә шул халәттә яши. Җитмәсә үзен белгән һәркем аны ялгыш адым ясавында гаепли.

ТӘКЪДИР СЫНАВЫ

Люция ХӘБИБУЛЛИНА

Саимә авылга әбиләренә кунакка кайткан җиреннән күрше егете Нәгыйм белән танышып очраша башлый. Икесе дә утыз яшьтән узгангадыр, туганнары аларның өйләнешүләренә дә каршы килми. Туйлар үткәргәннән соң егет тә шәһәргә күчеп китә. Ананы атна саен кайтып сөендерәсе урынга, Нәгыйм елга бер генә кайтып китә башлый. Гөлҗиһан апаның күрше хатыны белән сөйләшкәндә: «Бу Саимә улымны әллә нишләтте», – дигән сүзләре яшен тизлегендә киленгә дә барып ирешә. Саимәгә шул сүз җитә кала. Шуннан соң Нәгыймне дә авылга өч ел аяк бастырмый. Энесе, аның янына барып: «Абый, сиңа ничек оят түгел, йөз чакрым гына юл бит, ичмаса безнең белән әнинең хәлен белеп килер идең», – дигәч кенә, олы улы белән кайтырга була.

Саимә ирен бер-бер артлы дүрт бала табып сөендерә. 50 яшенә җиткәндә бишенчесен дә алып кайтырга җыенуын әйткәч, Нәгыйм аңа каршы килә. Шул чакта туганнарының, иренең сүзенә дә колак салмыйча тәвәккәлли ул. Моннан унсигез ел элек июнь аенда, таң алдыннан аның нарасые дөньяга аваз сала. Беренче мәртәбә үзенең кулына тоттырган сабыен ул шунда ук уртанчы улына охшатып кала. Температурасы күтәрелеп китү сәбәпле, Саимәгә икенче көнне баласын китермиләр. Өченче көнне исә шәфкать туташы кулыннан баланы алуга, йөрәге «жу» итеп китә аның. Язылган кәгазен дә кат-кат укый. «Бу минем бала түгел бит», – дип, шунда ук кычкырып та җибәрә. Аннары табиб янына барып башка балаларны да күрсәтүләрен үтенә. Әмма беренче көнне кулларына алып имезгән баланы башка күрми ул.

Бала тудыру йортыннан чыгуга ук ире белән икесе дә ДНК анализы биреп тикшертсәләр, баланың аларныкы булмавы ачыклана. Әмма алга таба үзләренең хокукларын яклап йөри алмый алар. Баланың даун чире белән авыруы билгеле була. Нәгыйм аны инвалидлар йортына бирергә кушса да, Саимә ризалашмый. Гөнаһыннан курка.

Бервакыт бер мәҗлестә янында утырган хатын-кызның сөйләшүе аның колагына керә. Моннан ике ел элек танышларының бала тудыру йортыннан үзләренең балаларын алыштырып чыгулары турында сөйли ул. Шунда Саимә әлеге гаиләнең кайда яшәвен сорашып, икенче көнне аларга юл тота. Ике катлы коттедж янында баласы белән йөргән хатыннан әлеге йортта кемнәр яшәвен сораша башласа, хуҗа хатын үзе булып чыга. Шулчак арбада яткан баланың үз балаларына охшаган булуына игътибар итә ул. Саимә үткән хәлләрне сөйли башлауга, хатын өенә ашыга. Ул аның башка үзләрен борчып йөрмәвен үтенә. Бу хакта Нәгыймгә дә әйтми Саимә.

18 яшенә кадәр авыру карау Нәгыймне дә, башка балаларын да туйдыра. Ата кеше бер улы белән гаиләдән китеп бара. Кызлары кияүгә чыга. Саимә исә унсигез ел буе тәрбияләп авыру бала авызыннан бер генә юньле сүз ишетмәвенә борчылып яши. Еламаган көне юк аның. Авыл халкы, каенанасы Гөлҗиһан апаның рәнҗеше төшкәндер, дип тә сөйләнә. Саимә баласын эзләүне ярты юлда калдыруына үкенеп бетә алмый. Ә хәзер аны табып, үзе белән очрашу мизгелләрен күз алдына да китерми ул.

Сәхифәне Илсөя ЗӘЙНУЛЛИНА әзерләде

ТЕЛЕманзара

ДҮШӘМБЕ
7 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30 М/с «Морские псы»
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30 «Яңа ел бүләге». «Казан егетләре» төркеме җырлый (12+)
11.00 «Новогодние приключения Барсиков». Республиканская детская Елка (6+)
12.00 Т/с «СИНИЕ НОЧИ» (12+)
14.00, 18.30, 21.30 00 Новости Татарстана (12+)
14.20 Т/ф «Софрино: мастерские чуда» (12+)
14.30 Т/с «ДЖИВС И ВУСТЕР» (12+)
17.00, 20.00 00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
19.00 «Посмотри, как я умею!» (12+)
19.30 «Хөршидә-Мөршидә». Юмористик таләшыру (12+)
19.45 «Караоке татарча» (12+)
20.30 «Халкым минем...» (12+)
21.00 «Күчтәнәч» (0+)
21.15 «Хочу мультфильм!» (0+)
22.00 Х/ф «КТО ПРОХОДИТ В ЗИМНИЙ ВЕЧЕР» (12+)
00.00 «Видеоспорт» (12+)
00.30 «Романсы к рождеству» (0+)
01.30 «Татар моңы-2012». Гала-концерт (12+)

ТАТАРСТАН
12.00 «Вести-Татарстан»

1 КАНАЛ
06.00 Новости
06.10 «Новогодний смех» на Первом
06.40 Х/ф «НАЗАД К СЧАСТЬЮ, ИЛИ КТО НАЙДЕТ СИНЮЮ ПТИЦУ»
08.45 «Новогодняя елка в Кремле»
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.10 «Золушка» (S)
11.30 «Ералаш»
12.15 «Время обедать!» Праздничный выпуск
12.55 Х/ф «МОРОЗКО»
14.30 Х/ф «ЗИМНИЙ РОМАН»
16.00 Х/ф «НОВОГОДНИЙ ПЕРЕПОЛОХ» (16+)
19.45 «Рождественские встречи» Аллы Пугачевой (S)
21.00 «Время»
21.15 «Рождественские встречи» Аллы Пугачевой. Продолжение (S)
22.35 Х/ф «РОМАН С КАМНЕМ»
00.35 Х/ф «ПОКА ТЫ СПАЛ» (12+)
02.35 Х/ф «КАБИНЕТНЫЙ ГАРНИТУР»
04.30 Т/с «24 ЧАСА» (16+)

РОССИЯ
06.35 Х/ф «РОДНЯ»
08.25, 11.15 Х/ф «НЕ ОТРЕКАЮТСЯ ЛЮБЯ...» (12+)
11.00, 14.00, 20.00 Вести
12.00 М/ф «Падал прошлогодний снег»
12.20 М/ф «Маша и Медведь»
12.45 Премьера. «Рождественская «Песенка года»
14.10 Премьера. «Война и мир Александра Первого. Наполеон против России. Изгнание»
15.30 Премьера. «Новая волна-2012». Лучшее
16.50 Премьера. «Смеяться разрешается». Юмористическая программа
18.00 «Новые приключения Аладдина»
20.20 Х/ф «ВАРЕНЬКА. И В ГОРЕ, И В РАДОСТИ» (12+)
01.05 Х/ф «АС» (16+)
02.40 Х/ф «КОСМИЧЕСКИЕ КОВБОИ» (16+)

НТВ
06.10 Х/ф «УБИТЬ ВЕЧЕР» (12+)
08.05 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
09.05 Премьера. «Детское радио-5 лет в эфире» (0+)
10.00, 13.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Таинственная Россия: Москва. Матрона - заступница столицы?» (16+)
11.10, 13.20 Т/с «БРАТЬЯ» (16+)
19.25 Т/с «ПАУТИНА». «КОЛЛЕКЦИОНЕР» (16+)
23.25 Х/ф «ЖИЛ-БЫЛ ДЕД» (16+)
01.25 «Концертный зал НТВ» представляет: Бенефис Ирины Понаровской» (12+)
03.20 Х/ф «МАСКВИЧИ» (16+)
04.10 Т/с «ХРАНИТЕЛЬ» (16+)

ЗВЕЗДА
06.00 Х/ф «СВИНАРКА И ПАСТУХ» (12+)
07.40 МУЛЬТФИЛЬМЫ
09.10 Д/с «Колеса Страны Советов. Были и небылицы». «В поисках движущей силы» (12+)
10.20 Х/ф «ТРИ ДНЯ В МОСКВЕ» (12+)
13.00, 18.00 НОВОСТИ
13.15, 19.30 Т/с «ВЕЧНЫЙ ЗОВ» (12+)
18.50 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
19.00 Новости «Столица» (KZN) (0+)
01.10 Т/с «ЧЕТЫРЕ ТАНКИСТА И СОБАКА» (12+)

КУЛЬТУРА
07.00 «Евроньюс» на русском языке
10.05 Х/ф «СКАЗКА О ЦАРЕ САЛТАНЕ»
11.30 Концерт «Путешествие в страну мультфильмов»
12.30 Х/ф «ОТЦЫ И ДЕДЫ»
13.50 «Планета Папанова». (*)
14.30 Михаил Барышников в балете П.И. Чайковского «ЩЕЛКУНЧИК». Постановка Американского Театра Балета
15.50 Х/ф «СВИНАРКА И ПАСТУХ»
17.10 Д/ф «Марина Ладынина»
17.55 Шлягеры ушедшего века. Владимир Васильев, Светлана Безродная, Александр Домогаров, Дмитрий Назаров, Сергей Полянский, Владимир Зельдин, Вера Васильева и Российский государственный академический камерный «Вивальди-оркестр» в концерте «Унесенные ветром»
19.30 Х/ф «ЗАЯЦ НАД БЕЗДНОЙ»
21.00 «Запечатленное время... «Кремлевские ёлки». (*)
21.30 Х/ф «ЗОЛУШКА»
00.55 «Терем-квартет». В кругу друзей.
01.40 «Искатели». «Тайны подземного Ростова». (*)
02.25 М/ф «Большой подземный бал». «Жил-был Козявин»

ЭФИР
05.00 Т/с «ЗОЛОТАЯ МЕДУЗА»
07.00 Концерт «Избранное». «Великие тайны»
10.00 «Ангел-хранитель» (16+)
11.00 «По секрету звезд» (16+)
12.00 «Дурман Вселенной» (16+)
13.00 «Бегущие в небеса» (16+)
14.00 «Звездные шепоты» (16+)
16.00 «Джентльмены удачи» (16+)
17.00 «45 секунд до вечности» (16+)
18.00 «Звездные двери» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 «Пришельцы из прошлого» (16+)
21.00 «Папа с Марса, мама с Венеры» (16+)
23.00 «Наложницы древних богов» (16+)
01.00 Т/с «МЕЧ»

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/ф «Наследство волшебника Бахрама». (0+) «Мышонок Пик». (0+) «Серебряное копытце»
07.55 М/с «Чаплин»
08.10 М/с «Смешарики» (0+)
08.20 М/с «Секретная служба Санты»
08.30 М/с «Флиппер и Лопака»
09.00 М/ф «Дед Мороз и Серый волк». (0+) «Снеговик-почтовик»
09.45 Х/ф «ДОЧЬ САНТЫ-2. РОЖДЕСТВЕНСКАЯ СКАЗКА» (12+)
11.30 М/ф «Рождественские истории»
14.15 «Кунг-фу Панда-2» (6+) Полнометражный анимационный фильм. США, 2011 г.
16.00, 16.30 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
17.25 «Кот в сапогах». (6+) Полнометражный анимационный фильм. США, 2011 г.
19.00 Х/ф «КЛИК. С ПУЛЬТОМ ПО ЖИЗНИ» (12+)
21.00 «ДНЕВНИК ДОКТОРА ЗАЙЦЕВОЙ» (16+)
22.00 Х/ф «ГОСПОЖА ГОРНИЧНАЯ» (16+)
00.00 Х/ф «ПОДАРКИ К РОЖДЕСТВУ» (12+)
01.50 Х/ф «ПТАШКА» (16+)
03.40 Т/с «СООБЩЕСТВО» (16+)
04.05 М/с «Скуби Ду»
05.35 Музыка на СТС (16+)

СПОРТ
05.00, 02.25 «Моя планета»
07.15 «Моя рыбалка»
07.40 «Диалоги о рыбалке»
08.10 «Язь против еды»
08.40, 01.10 «Большой тест-драйв со Стиллавиным»
09.25 «Рейтинг Баженова. Человек для опытов»
09.55 Хоккей. КХЛ. «Амур» (Хабаровск) - «Авангард» (Омская область). Прямая трансляция
12.15, 18.45 Вести-спорт
12.25, 01.00 Автоспорт. «Дакар-2013»
12.55 Биатлон. Кубок мира. Трансляция из Германии
16.25 «Братство кольца»
16.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Астана» (Казахстан) - «Химки» (Россия). Прямая трансляция
18.55 Х/ф «СТАЛЬНЫЕ ТЕЛА» (16+)
21.00 Х/ф «УДАРНАЯ СИЛА» (16+)
22.50 Х/ф «ЗАМЕНА» (16+)
01.55 «Русские байки. Кругосветное путешествие» (16+)

СИШӘМБЕ
8 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30,. 40 Т/с «ЛАПУШКИ» (12+)
09.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00 «Башваткыч» (12+)
12.00 Т/с «СИНИЕ НОЧИ» (12+)
14.00, 21.30 00 Новости Татарстана (12+)
14.15 «Путь» (12+)
14.35 «ЖКХ: сколько стоит ОДН?» (12+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Тамчы-шоу» (6+)
16.00 «Яшьләр тукталышы» (12+)
16.30 «Газпром трансгаз Казань. Итоги года» (12+)
17.00, 20.00 00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак Барс» (Казань) - «СКА» (Санкт-Петербург). Трансляция из Казани (+12)
19.45 «Бакировский сюрприз» (12+)
20.30 «Посмотри, как я умею!» (12+)
22.00 Х/ф «ОЛИГАРХ»
00.10 «Автомобиль» (12+)
01.30 «Татар моңы-2012». Гала-концерт (12+)

1 КАНАЛ
05.25, 06.10 Х/ф «ПО УЛИЦАМ КОМОД ВОДИЛИ»
06.00 Новости
06.45 Х/ф «ОРЕЛ И РЕШКА» (12+)
08.20 Х/ф «ЖЕНИТЬБА БАЛЬЗАМИНОВА»
10.00, 12.00 Новости (с субтитрами)
10.10 Х/ф «СТАРИК ХОТТАБЫЧ»
11.45 «Ералаш»
12.15 Х/ф «ФРАНЦУЗ» (12+)
14.15 Премьера. «Еда как лекарство»
15.20 Х/ф «КАРНАВАЛ»
18.15 Новый год на Первом (S)
21.00 «Время»
21.15 Т/с «МЕТОД ФРЕЙДА» (16+)
23.10 Х/ф «ЖЕМЧУЖИНА НИЛА»
01.10 Х/ф «У КАЖДОГО СВОЯ ЛОЖЬ» (16+)
02.35 Х/ф «СИЦИЛИЙСКИЙ КЛАН» (16+)

РОССИЯ
04.45 Х/ф «РАЗ НА РАЗ НЕ ПРИХОДИТСЯ»
06.00 Х/ф «БОЛЬШАЯ ПЕРЕМЕНА»
11.00, 14.00, 20.00 Вести
11.15 Евровидение- 2012 г. «Волшебный цирк детей Европы»
13.00, 14.15 Т/с «БИЛЕТ В ГАРЕМ» (12+)
20.20 Х/ф «НЕПУТЕВАЯ НЕВЕСТКА» (12+)
00.00 Х/ф «БАРХАТНЫЕ РУЧКИ» (16+)
01.45 Х/ф «УСТРИЦЫ ИЗ ЛОЗАННЫ» (16+)
03.10 Х/ф «С ПОЧЕСТЯМИ» (16+)

НТВ
06.10 Т/с «АГЕНТ НАЦИОНАЛЬНОЙ БЕЗОПАСНОСТИ» (16+)
08.00 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
09.00 Кулинарный поединок с Оскаром Кучерой (0+)
10.00, 13.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Таинственная Россия: Север. Загадки древних цивилизаций?» (16+)
11.10, 13.20 Т/с «БРАТЬЯ» (16+)
19.25 Т/с «ПАУТИНА». «БОЕЦ» (16+)
23.30 Х/ф «ЗАПРЕТ НА ЛЮБОВЬ» (16+)
01.25 Квартирный вопрос (0+)
02.25 Т/с «ОТРАЖЕНИЯ» (16+)
03.55 Х/ф «МАСКВИЧИ» (16+)
04.55 Т/с «ХРАНИТЕЛЬ» (16+)

ЗВЕЗДА
06.00 Х/ф «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» (12+)
07.50 Х/ф «ПОДАРОК ЧЕРНОГО КОЛДУНА»
09.00 МУЛЬТФИЛЬМЫ
09.10 Д/с «Колеса Страны Советов. Были и небылицы». «Легенда среднего класса» (12+)
10.15 Х/ф «ШОФЕР НА ОДИН РЕЙС» (12+)
13.00, 18.00 НОВОСТИ
13.15, 18.15 Т/с «ВЕЧНЫЙ ЗОВ» (12+)
18.50 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
19.00 Новости «Столица» (KZN) (0+)
00.15 Х/ф «ТРИ ДНЯ В МОСКВЕ» (12+)
02.50 Т/с «ЧЕТЫРЕ ТАНКИСТА И СОБАКА» (12+)
05.10 Д/ф «Конец фильма» (16+)

КУЛЬТУРА
06.30 «Евроньюс» на русском языке
10.00 Новости культуры
10.20 М/ф «Двенадцать месяцев». «В некотором царстве...»
11.40 «Цирк Массимо»
12.35 Х/ф «БЛАГОЧЕСТИВАЯ МАРТА»
14.55 «Русские потехи». Государственный академический русский народный хор имени М. Е. Пятницкого и фольклорные ансамбли в КЗЧ
16.15, 01.00 Д/ф «Ненетт»
17.10 «Искатели». «Тайны подземного Ростова». (*)
18.00 Вспоминая Федора Хитрука. Авторская анимация: «История одного преступления», «Фильм, фильм, фильм», «Остров», «Дарю тебе звезду», «Лев и Бык», «Икар и мудрецы»
19.15 Х/ф «ЗИМНИЙ ВЕЧЕР В ГАГРАХ»
20.40 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №1
21.25, 01.55 Д/с «Метроном. История Франции»
22.25 Х/ф «ЭДИТ И МАРСЕЛЬ»
02.50 Д/ф «Кацусика Хокусай»

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 20.00, 23.00 Т/с «МЕЧ»
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
00.30 Х/ф «КАМЕННАЯ БАШКА»
02.30 Х/ф «ВО ВСЕОРУЖИИ»
04.10 «Великие тайны» с Игорем Прокопенко «Наследники дьявола» До 05.00 (16+)

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/ф «Последний лепесток». (0+) «Умка». (0+) «Умка ищет друга»
07.55 М/с «Чаплин»
08.10 М/с «Смешарики» (0+)
08.30 М/с «Флиппер и Лопака»
09.00 М/ф «Ну, погоди!» (0+) «Новогодняя сказка»
09.30 М/ф «Том и Джерри встречают Шерлока Холмса» 2010 г.
10.30 «Рождественская история». Полнометражный анимационный фильм. США, 2009 г. (12+)
12.20 Х/ф «САНТА КЛАУС-2» (12+)
14.15 Х/ф «САНТА КЛАУС-3. ХОЗЯИН ПОЛЮСА» (12+)
16.00, 16.30 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
17.10 Х/ф «ГОСПОЖА ГОРНИЧНАЯ» (16+)
19.10 Х/ф «МИЛЛИОНЕР ПОНЕВОЛЕ» (16+)
21.00 «ДНЕВНИК ДОКТОРА ЗАЙЦЕВОЙ» (16+)
22.00 Х/ф «МУЖЧИНА В МОЕЙ ГОЛОВЕ» (16+)
00.20 «КОГДА САНТА УПАЛ НА ЗЕМЛЮ» (12+)
02.20 Х/ф «СУМАСШЕДШИЙ НА ВОЛЕ» (16+)
04.10 М/с «Скуби Ду»
05.40 Музыка на СТС (16+)

СПОРТ
05.00, 02.30 «Моя планета»
07.05 «Моя рыбалка»
07.35 «Диалоги о рыбалке»
08.05 «Язь против еды»
08.30, 01.10 «Большой тест-драйв со Стиллавиным»
09.20 «Рейтинг Баженова. Человек для опытов»
09.45 Х/ф «ЗАМЕНА» (16+)
12.00, 19.45 Вести-спорт
12.10, 01.00 Автоспорт. «Дакар-2013»
12.40 Х/ф «СТАЛЬНЫЕ ТЕЛА» (16+)
14.55 Хоккей. КХЛ. «Салават Юлаев» (Уфа) - «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
17.25 Хоккей. КХЛ. «Ак Барс» (Казань) - СКА (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
19.55 Профессиональный бокс
21.30 Смешанные единоборства (16+)
23.10 Х/ф «ТУРБУЛЕНТНОСТЬ» (16+)
02.00 «Русские байки. Кругосветное путешествие» (16+)
02.55 Хоккей. КХЛ. «Локомотив» (Ярославль) - «Динамо» (Минск)

ЧӘРШӘМБЕ
9 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30,0 .30 Т/с «ЛАПУШКИ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30, 01.30 00 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
11.00 «Татар халык җырлары (0+)
11.30 «Халкым минем...» (12+)
12.00 Д/ф «Проклятие фараонов» (12+)
13.00 «Секреты татарской кухни» (12+)
13.30 «Среда обитания» (12+)
14.00, 18.30 00 Новости Татарстана (12+)
14.20 «Актуальный ислам» (6+)
14.25 «Нәсыйхәт» (6+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00, 21.00 00 «Хочу мультфильм!» 0+)
15.15, 21.15 00 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Без - Тукай оныклары» (6+)
15.45 «Һөнәр» (6+)
16.00 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16.25 Т/с «МАГНА АУРА»
17.00, 21.30 00 Татарстан хәбәрләре (12+)
17.20 «Елмай!» (12+)
19.00 Волейбол. «Зенит-Казань» - «Прикамье» (Пермь). Трансляция из Казани (6+)
22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (12+)
23.00 Т/с «БУЛЬВАРНЫЙ ПЕРЕПЛЕТ»
00.00 «Видеоспорт» (12+)
02.00 «Мәдәният дөньясында» (12+)

Туган җир

ТАТАРСТАН
06.05, 07.05, 08.05 «Вести - Татарстан. Погода»
06.35, 07.35, 08.35 «Вести - Татарстан. Утро»
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 «Вести - Татарстан»

1 КАНАЛ
05.00, 09.00, 03.00 Новости
05.05 «Доброе утро»
09.15 «Контрольная закупка»
09.45 «Жить здорово!» (12+)
10.55 «Модный приговор»
12.00, 15.00 Новости (с субтитрами)
12.20 «Время обедать!»
13.00 «Доброго здоровьица!» с Геннадием Малаховым (12+)
14.00 Другие новости
14.25 «Понять. Простить» (12+)
15.15 «Хочу знать» с Михаилом Ширвиндтом
15.50 «Дешево и сердито» с Дарьей Донцовой
16.35 Премьера. «Ты не один» (16+)
17.05 Т/с «НЕРАВНЫЙ БРАК» (16+)
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 «Угадай мелодию»
18.50 «Давай поженимся!» (16+)
19.55 «Пусть говорят» (16+)
21.00 «Время»
21.30 Т/с «МЕТОД ФРЕЙДА» (16+)
23.30 Ночные новости «Городские пижоны»
23.50 «Белый воротничок». Новые серии (S) Внимание! С 00.50 до 06.00 на Москву и Московскую область вещание осуществляется по кабельным сетям (16+)
00.50 Х/ф «ВЕЛИКОЛЕПНЫЙ» (16+)
02.45, 03.05 Х/ф «ОТСКОК» (12+)
04.25 «Контрольная закупка» до 04.55

РОССИЯ
05.00 Утро России
09.00 «1000 мелочей». Ток-шоу
09.45 «О самом главном». Ток-шоу
10.30 «КУЛАГИН И ПАРТНЕРЫ». (12+)
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30, 14.30, 17.30, 19.40 Вести-Москва
11.50 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ». (12+)
13.50, 16.45 Вести. Дежурная часть
14.50 Т/с «ВЕСНА В ДЕКАБРЕ» (12+)
17.50, 21.30 Т/с «ЛИКВИДАЦИЯ» (12+)
20.30 Спокойной ночи, малыши!
20.40 «Прямой эфир». (12+)
00.10 Премьера. «Солдат империи». Внимание! С 01.45 до 06.00 вещание на Москву и Московскую область осуществляется по кабельным сетям
01.05 Х/ф «ЧОКНУТЫЕ» (16+)
03.05 Х/ф «ЗАКОН РАНДАДУ» (16+)

НТВ
06.00 Информационный канал «НТВ утром»
08.05 Т/с «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (16+)
10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня
10.20 «Живут же люди!» (0+)
10.55 «До суда» (16+)
12.00 Суд присяжных (16+)
13.25 «Суд присяжных. Окончательный вердикт» (16+)
14.35 Т/с «СУПРУГИ» (16+)
15.30, 18.30 Обзор. Чрезвычайное происшествие
16.25 «Прокурорская проверка» (16+)
17.40 «Говорим и показываем». Ток-шоу с Леонидом Закошанским (16+)
19.30 Т/с «ПАУТИНА» (16+)
23.30 Т/с «РУССКИЙ ДУБЛЬ» (16+)
01.35 Т/с «ОТРАЖЕНИЯ» (16+)
02.40 Дикий мир (0+)
03.00 Т/с «ЕЩЕ НЕ ВЕЧЕР» (16+)
04.55 Т/с «ХРАНИТЕЛЬ» (16+)

ЗВЕЗДА
06.00 «Дороже золота» (16+)
06.20, 18.50, 21.20 «Чрезвычайка» (KZN) (16+)
06.30, 14.00, 19.00, 21.30 Новости «Столица» (KZN) (0+)
07.10 Х/ф «ЦИРК» (12+)
09.00, 13.00, 16.00, 18.00, 22.00 НОВОСТИ
09.15 Д/с «Погоня за скоростью» (12+)
10.15 Х/ф «И НА КАМНЯХ РАСТУТ ДЕРЕВЬЯ» (16+)
13.15 Д/с «Товарищ комендант». «Комендант «Маленькой Москвы» (12+)
14.25 Д/с «Оружие XX века» (16+)
15.00, 16.15 Т/с «МОРСКОЙ ПАТРУЛЬ» (16+)
17.20 Д/с «Битва империй» (16+)
19.30 Х/ф «КАРЬЕРА ДИМЫ ГОРИНА» (12+)
22.30 Х/ф «ИЩИ ВЕТРА...» (12+)
00.00 Х/ф «ПОЗДНЯЯ ВСТРЕЧА» (12+)
01.45 Чемпионат России по мини-футболу. Суперлига. 11-й тур. «Динамо» - «Дина»
03.35 Х/ф «СВЕТЛЫЙ ПУТЬ» (12+)
05.30 Д/с «Невидимый фронт» (16+)

КУЛЬТУРА
06.30 «Евроньюс» на русском языке
10.00 «Наблюдатель»
11.15 Х/ф «ДЕТИ ДОН-КИХОТА»
12.35 Д/ф «Хор Жарова»
13.05 «Острова»
13.45, 18.35 Д/с «Клетка, или Из чего состоит жизнь»
14.40 «Русский Леонардо. Павел Флоренский»
15.10 Красуйся, град Петров! Зодчий Джакомо Кваренги. (*)
15.40, 19.30, 23.35 Новости культуры
15.50 Спектакль «ДОКТОР ФИЛОСОФИИ»
17.15 Д/ф «Мировые сокровища культуры». «Исфахан. Зеркало рая»
17.35 Виртуозы Богемии
19.45 Главная роль
20.00 Д/ф «Магистрали жизни»
20.40 «Полиглот». Французский с нуля за 16 часов! №2
21.25, 01.40 Д/с «Метроном. История Франции»
22.20 Магия кино. Ведущие М. Борзенков и О. Шишкин
23.05 «Те, с которыми я... Профессия - кинохудожник. Александр Борисов». Авторская программа Сергея Соловьева. 1 часть (*)
00.00 Х/ф «ДВОЙНАЯ ЖИЗНЬ ВЕРОНИКИ»
01.35 Д/ф «Леся Украинка»
02.35 Играет Барри Дуглас.

ЭФИР
05.00 «УТРО» (16+)
08.30, 12.30 «Новости 24» (16+)
08.45 Х/ф «ОСОБЕННОСТИ НАЦИОНАЛЬНОЙ ОХОТЫ»
10.30 Х/ф «ОСОБЕННОСТИ НАЦИОНАЛЬНОЙ РЫБАЛКИ»
13.00 «Званый ужин» (16+)
14.00 «Семейные драмы» (16+)
19.00, 22.00 «Информационный час: Программа ГОРОД» (16+)
20.00 «Специальный проект»: «Ночь после судного дня» (16+)
23.00 «Специальный проект»: «Роковая любовь» (16+)
01.00 Х/ф «ОЧЕНЬ СТРАШНОЕ КИНО»
02.30 Х/ф «БЕСПУТНАЯ РОЗА»
04.40 «Дураки, дороги, деньги» До (16+)

СТС-КАЗАН
06.00 М/с «Гуфи и его команда»
07.00 М/с «Великий Человек-паук» (12+)
07.30 М/с «Чародейки» (12+)
08.00 «ПАПИНЫ ДОЧКИ» (12+)
08.30 «СВЕТОФОР» (16+)
09.00, 13.20, 13.30, 14.00, 19.00, 23.45, 00.00, 00.30 Т/с «6 КАДРОВ» (16+)
09.30, 21.00 «ДНЕВНИК ДОКТОРА ЗАЙЦЕВОЙ» (16+)
10.30 Х/ф «МИЛЛИОНЕР ПОНЕВОЛЕ» (16+)
12.20, 16.30 Т/с «ДАЁШЬ МОЛОДЁЖЬ!» (16+)
14.10 «МУЖЧИНА В МОЕЙ ГОЛОВЕ» (16+)
17.00, 18.30 «ВОРОНИНЫ» (16+)
19.20 Х/ф «ЛЖЕЦ, ЛЖЕЦ» (12+)
22.00 Х/ф «СТРАШНО КРАСИВ» (12+)
01.45 Х/ф «ПОСЛЕДНЯЯ ПЕСНЯ» (16+)
03.45 Т/с «СООБЩЕСТВО» (16+)
04.10 М/с «Скуби Ду»
05.40 Музыка на СТС (16+)

СПОРТ
05.00, 08.05 «Все включено» (16+)
05.50, 02.30 «Моя планета»
07.00, 09.00, 12.00, 20.50 Вести-спорт
07.10 «Моя рыбалка»
07.40 «Язь против еды»
09.10 Х/ф «ТУРБУЛЕНТНОСТЬ» (16+)
11.00 «Наука 2.0. ЕХперименты». Повелители молний
11.30 «Наука 2.0. Опыты дилетанта». Люди-золото
12.10, 01.00 Автоспорт. «Дакар-2013»
12.40 Х/ф «ЗАМЕНА» (16+)
14.55 Х/ф «БЕЗ ТОРМОЗОВ» (16+)
15.25 Хоккей России
15.55 Хоккей. КХЛ. «Металлург» (Новокузнецк) - «Авангард» (Омская область). Прямая трансляция
18.15 Профессиональный бокс. Денис Лебедев (Россия) против Сантандера Сильгадо (Колумбия). Бой за титул чемпиона мира в первом тяжелом весе по версии WBA
18.50 Х/ф «БОЙ НАСМЕРТЬ» (16+)
21.05 Биатлон. Кубок мира. Эстафета. Женщины. Прямая трансляция из Германии
22.45 «Полигон»
23.15 Х/ф «ДЕВЯТЬ ЖИЗНЕЙ» (16+)
01.10 «Большой тест-драйв со Стиллавиным». Внимание! С 01.45 до 06.00 вещание на Москву и Московскую область осуществляется по кабельным сетям
02.00 «Русские байки. Кругосветное путешествие» (16+)
03.10 Волейбол. Чемпионат России. Мужчины. «Газпром-Югра» (Сургутский район) - «Динамо» (Москва)

ПӘНҖЕШӘМБЕ
10 ГЫЙНВАР

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
07.30 «Доброе утро!»
08.30 Т/с «ЛАПУШКИ» (12+)
09.30, 17.30 Т/с «МӘХӘББӘТ ШӘРАБЫ» (12+)
10.30 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт 0+
11.00 «Кара-каршы» (12+)
12.00, 22.00 Т/с «ЭЗЕЛЬ» (12+)
13.00 «В поисках разума».Из цикла «Вселенная» (12+)
14.00, 18.30, 21.30 00 Новости Татарстана (12+)
14.15. 00 00 «Волейбол». Тележурнал (12+)
14.45 «Путь» (12+)
14.55 «Тиззарядка» (0+)
15.00, 21.15 00 «Хочу мультфильм!» (0+)
15.15, 21.00 00 «Күчтәнәч» (0+)
15.30 «Мәктәп» (6+)
15.45 «Көлдермеш» (6+)
16.00 «Tat-music» (12+)
16.25 Т/с «МАГНА АУРА»
17.00, 20.00 00 Татарстан хәбәрләре (12+)
